Шагыйрь Яков Емельяновның тууына 170 ел (1848–1893)

– 170 лет со дня рождения поэта Якова Емельянова ((1848–1893) (См.: Татарстан: Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре=Календарь знаменательных и памятных дат. 1998. – Казань: Милли китап, 1998. – С.101-104)

Шагыйрь Габделмәннан Рахманколыйның тууына 160 ел (1858–1908)

– 160 лет со дня рождения поэта Габдельманнана Рахманкулыя (Рахманкулова) (1858–1908)

Нашир, журналист Заһид (Мөхәммәтзаһид) Мөхәммәдшәфи улы Шамилнең тууына 150 ел (1868–1920). «Тәрбиятел-әтфаль» журналы нашире һәм мөхәррире. 1907–1917 елларда нәшер ителгән татар китапларының библиографиясен төзүче

– 150 лет со дня рождения издателя, журналиста Загида (Мухаммадзагида) Мухаммадшафиевича Шамиля (1868–1920). Издатель и редактор журнала «Тарбиятуль-атфаль», составитель библиографии татарской книги (1907–1917)

Казан университетында Казан табиблар җәмгыяте төзелүгә 150 ел (1868)

– 150 лет со дня основания Казанского общества врачей при Казанском университете (1868)

Гарәп теле белгече, журналист, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Закир Хәлим улы Кадыйриның тууына 140 ел (1878–1954)

– 140 лет со дня рождения востоковеда, журналиста, общественно-политического деятеля Закира Халимовича Кадыри (1878–1954)

Казан университетында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте төзелүгә 140 ел (1878)

– 140 лет со дня основания Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете (1878)

Әдип, тәрҗемәче һәм сүзлекләр авторы, журналист Солтан Габделмәннан улы Рахманколый (Рахманкулов)ның тууына 130 ел (1888–1916)

– 130 лет со дня рождения писателя, переводчика, автора словарей, журналиста Султана Габделманнановича Рахманкулыя (Рахманкулова) (1888–1916)

Шагыйрь һәм драматург Кәрим Хөсәен улы Әмиринең (Әмиров)ның тууына 125 ел (1893–1962)

– 125 лет со дня рождения поэта и драматурга Карима Хусаиновича Амири (Амирова) (1893–1962)

Шагыйрь Ибраһим Йосыф улы Башмаковның тууына 125 ел (1893–1913)

– 125 лет со дня рождения поэта Ибрагима Юсуфовича Башмакова (1893–1913)

Шагыйрә, мөгаллимә Мәхмүдә Хуҗахмәд кызы Мозаффариянең (Урманчиеваның) тууына 125 ел (1893–1969)

– 125 лет со дня рождения поэтессы, педагога Махмуды Ходжа-Ахмадовны Музаффарии (Урманчеевой) (1893–1969)

Шагыйрь, журналист Габдулла Харис улы Харис (Харисов)ның тууына 125 ел (1893–1931)

– 125 лет со дня рождения поэта, журналиста Габдуллы Харисовича Хариса (Харисова) (1893–1931)

Шагыйрь, театр тәнкыйтьчесе Төхфәт Ченәкәйнең (Төхфәтулла Гыйззәтуллинның) тууына 125 ел (1893–1959)

– 125 лет со дня рождения поэта, театрального критика Тухфата Ченекая (Тухфатуллы Гиззатуллина) (1893–1959)

Шагыйрь Мансур Кәрим улы Крыймовның тууына 120 ел (1898–1938)

– 120 лет со дня рождения поэта Мансура Каримовича Крымова (1898–1938)

Музыкант, күренекле мандолиначы Исмәгыйль Гобәйдулла улы Һилаловның тууына 120 ел (1898–1992)

– 120 лет со дня рождения музыканта Исмагила Губайдулловича Хилалова (1898–1992)

Яшел Үзән (Зеленодольск) шәһәрендә «Серго исемендәге завод» («Позис») җитештерү берләшмәсе төзелүгә 120 ел (1898)

– 120 лет со дня основания Зеленодольского производственного объединения «Завод имени Серго» («Позис») (1898) (См.: Татарстан: Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре=Календарь знаменательных и памятных дат. 1998. – Казань: Милли китап, 1998. – С.106-108)

Шагыйрь Аитзак Аитовның тууына 110 ел (1908–1941)

– 110 лет со дня рождения поэта Аитзака Аитова (1908–1941)

Шагыйрь Әхтәм Әмин улы Әминевның тууына 100 ел (1918–1942)

– 100 лет со дня рождения поэта Ахтяма Аминовича Аминова (1918–1942)

«Татарстан Республикасы матбугат елъязмасы» исемле дәүләт библиографик күрсәткече чыга башлауга 80 ел (1938)

– 80 лет со дня начала издания государственного библиографического указателя «Летопись печати Республики Татарстан» (1938)

**Түбәндә исемнәре күрсәтелгән**
**якташларыбыз – Советлар Союзы**
**Геройларының 2018 елда юбилейлары була:***

**В 2018 году исполняется Героям**
**Советского Союза – нашим землякам:****

Петр Егорович Воробьевның тууына 110 ел (08.07.1908–1984)
– 110 лет со дня рождения Петра Егоровича Воробьева (08.07.1908–1984)

Әхмәтсафа Гайсә улы Гайсинның тууына 100 ел (1918–1943)
– 100 лет со дня рождения Ахметсафы Гайсовича Гайсина (1918–1943)

Павел Яковлевич Гурьяновның тууына 100 ел (15.12.1918–1960).
– 100 лет со дня рождения Павла Яковлевича Гурьянова (15.12.1918–1960)

Селиверст Васильевич Давыдовның тууына 100 ел (15.01.1918–1992)
– 100 лет со дня рождения Селиверста Васильевича Давыдова (15.01.1918–1992)

Зиннәтулла (Зиновий) Гыйниятулла улы Исхаковның тууына 110 ел (17.08.1908–1958)
– 110 лет со дня рождения Зиннатуллы Гиниатулловича (Зиновия Генатулловича ) Исхакова (17.08.1908-1958)

Александр Васильевич Кирсановның тууына 120 ел (23.12.1898–1994)
– 120 лет со дня рождения Александра Васильевича Кирсанова (23.12.1898–1994)

Александр Максимович Меркушевның тууына 100 ел (14.11.1918–1991)
– 100 лет со дня рождения Александра Максимовича Меркушева (14.11.1918–1991)

Михаил Петрович Панаринның тууына 100 ел (1918–1943)
– 100 лет со дня рождения Михаила Петровича Панарина (1918–1943)

Алексей Павлович Панфиловның тууына 120 ел (1898–1966)
– 120 лет со дня рождения Алексея Павловича Панфилова (1898–1966)

Дмитрий Карпович Приваловның тууына 110 ел (1908–1943)
– 110 лет со дня рождения Дмитрия Карповича Привалова (1908–1943)

Леонид Михайлович Соколовның тууына 110 ел (28.04.1908–1982)

– 110 лет со дня рождения Леонида Михайловича Соколова (28.04.1908–1982)

Никита Евдокимович Токарликовның тууына 100 ел (1918–1945)
– 100 лет со дня рождения Никиты Евдокимовича Токарликова (1918–1945)

Ислам Рәхим улы Халиковның тууына 100 ел (15.11.1918–1944)
– 100 лет со дня рождения Ислама Рахимовича Халикова (15.11.1918–1945)

Михаил Алексеевич Чирковның тууына 120 ел (1898–1945)
– 120 лет со дня рождения Михаила Алексеевича Чиркова (1898–1945)

Алексей Петрович Чулковның тууына 110 ел (1908–1942)
– 110 лет со дня рождения Алексея Петровича Чулкова (1908–1942)

Петр Сергеевич Юхвитовның тууына 100 ел (1918–1944)
– 100 лет со дня рождения Петра Сергеевича Юхвитова (1918–1944)

---

*** Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**

Ханин Л. Советлар Союзы Геройлары – Татарстан уллары. – Казан: Татар. китап нәшр., 1966. – 640 б.

Советлар Союзы геройлары – якташларыбыз: әдәби докум. очерклар һәм язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 680 б.

**** Очерки о жизненном пути Героев см.:**

Герои Советского Союза – наши земляки: сб. докум. очерков и зарисовок: в 3-х кн. /сост. З.И.Гильманов, А.К.Айнутдинов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982–1985.

Батырлар китабы = Книга Героев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 395 б. – На татар. и рус. яз.

Ханин Л. Герои Советского Союза – сыны Татарии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1963. – 680 с.

**Түбәндә исемнәре күрсәтелгән якташларыбыз – Дан орденының тулы кавалерларының 2018 елда юбилейлары була:***

**В 2018 году исполняется кавалерам ордена Славы трех степеней – нашим землякам:***

Алексей Афанасьевич Васильевның тууына 100 ел (17.03.1918–1971)
– 100 лет со дня рождения Алексея Афанасьевича Васильева (17.03.1918–1971)

Петр Иванович Малкинның тууына 100 ел (30.09.1918–1980)
– 100 лет со дня рождения Петра Ивановича Малкина (30.09.1918–1980)

Хаҗи Миңнекәй улы Миңнекәевнең тууына 100 ел (05.03.1918–1992)
– 100 лет со дня рождения Хази Минникаевича Минникаева (05.03.1918–1992)

Миңлекасыйм Низаметдин улы Мөхәммәтҗановның тууына 100 ел (1918–?)
– 100 лет со дня рождения Минкассы (Минлекасима) Низамутдиновича Мухамедзянова (1918–?)

Ислам Насыйбулла улы Насыйбуллинның тууына 100 ел (10.10.1918–1981)
– 100 лет со дня рождения Ислама Насыбулловича Насыбуллина (10.10.1918–1981)

Гавриил Васильевич Сафоновның тууына 120 ел (25.03.1898–1976)
– 100 лет со дня рождения Гавриила Васильевича Сафонова (25.03.1898–1976)

Бәдретдин Садретдин улы Төхфәтулловның тууына 100 ел (15.06.1918–1988)
– 100 лет со дня рождения Бадретдина Садретдиновича Тухватуллова (15.06.1918–1988)

---

*** Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**
*** Очерки о жизненном пути Героев см.:**

Кавалеры ордена Славы трех степеней = Дан орденының тулы кавалерлары. – Казань: Книга Памяти, 2005. – 247 с. – На рус. и татар. яз.

**Түбәндә исемнәре күрсәтелгән якташларыбыз – Социалистик Хезмәт Геройларының 2018 елда юбилейлары була:***
**В 2018 году исполняется Героям Социалистического труда – нашим землякам:***

Галимулла Әсхәдулла улы Әсхәдуллинга 90 яшь (14.04.1928)
– 90 лет Галимулле Асхадулловичу Асхадуллину (14.04.1928)

Лотфулла Вәли улы Гыйззәтдиновның тууына 100 ел (14.02.1918–1982)
– 100 лет со дня рождения Лотфуллы Валиевича Гизатдинова (14.02.1918–1982)

Валентин Петрович Глушконың тууына 110 ел (02.09.1908–1989)
– 110 лет со дня рождения Валентина Петровича Глушко (02.09.1908–1989)

Сания Сабир кызы Заһировага 100 яшь (13.02.1918)
100 лет Сании Сабировне Загировой (13.02.1918)

Гөлсинә Хөснулла кызы Җантимеровага 75 яшь (06.03.1943)
– 75 лет Гулсине Хуснулловне Зантимеровой (06.03.1943)

Кәримулла Хәким улы Ибәтуллинның тууына 90 ел (06.03.1928–2011)
– 90 лет со дня рождения Каримуллы Хакимовича Ибатуллина (06.03.1928–2011)

Гөлбикә Гали кызы Кәримовага 80 яшь (15.09.1938)
– 80 лет Гульбике Галеевне Каримовой (15.09.1938)

Владимир Александрович Котельниковның тууына 110 ел (06.09.1908–2005)
– 110 лет со дня рождения Владимира Александровича Котельникова (06.09.1908–2005)

Владимир Алексеевич Левановның тууына 90 ел (1928–1981)
– 90 лет со дня рождения Владимира Алексеевича Леванова (1928–1981)

Вазил Салих улы Мәүликовның тууына 75 ел (30.10.1943–2015)
– 75 лет со дня рождения Вазила Салиховича Мавликова (30.10.1943–2015)

Николай Алексеевич Мальцевның тууына 90 ел (10.03.1928–2001)
– 90 лет со дня рождения Николая Алексеевича Мальцева (10.03.1928–2001)

Илдус Шәйхелислам улы Мостюковка 90 яшь (06.03.1928)
– 90 лет Ильдусу Шайхулисламовичу Мостюкову (06.03.1928)

Сергей Егорович Немасевның тууына 90 ел (25.09.1928–2006)
– 90 лет со дня рождения Сергея Егоровича Немасева (25.09.1928–2006)

Владимир Геннадьевич Садовниковның тууына 90 ел (25.01.1928–1990)
– 90 лет со дня рождения Владимира Геннадьевича Садовникова (25.01.1928–1990)

Георгий Степанович Сторожевның тууына 100 ел (1918–?)
– 100 лет со дня рождения Георгия Степановича Сторожева (1918–?)

Даһи Гарифулла улы Шәрифуллинның тууына 90 ел (15.07.1928–2003)
– 90 лет со дня рождения Даги Гарифулловича Шарифуллина (15.07.1928–2003)

---

*** Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**
*** Очерки о жизненном пути Героев см.:**

Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы – наши земляки = Социалистик Хезмәт геройлары һәм Хезмәт даны орденының тулы кавалерлары – безнең якташларыбыз. – Казань, 2003. – 232 с. – На рус. и татар. яз.

Герои Труда Татарии 1920–1938 гг.: док. очерки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 304 с.

Герои Социалистического Труда (1938–1978 гг.): (док. очерки). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – 383 с.

Герои Социалистического Труда Татарии: док. очерки. Кн.2. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 352 с.

**16 гыйнвар** **Шиһабетдин Мәрҗани**
**16 января** **Шигабутдин Марджани**
**1818–1889**
**тууына 200 ел**
**200 лет со дня рождения**

Мәгърифәтче, дин белгече, тарихчы, фәлсәфәче, шәркыять галиме, педагог Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани 1818 елның 16 гыйнварында Казан губернасы Казан өязенең (хәзер Татарстанның Әтнә районы) Ябынчы авылында дини гаиләдә туа. Башлангыч белемне әтисе укыткан Ташкичү мәдрәсәсендә ала. Яшь Шиһабетдин өйләрендәге китапханәдә мөстәкыйль рәвештә дә шөгыльләнә. 17 яшендә инде ул әлеге мәдрәсәдә укыта башлый.

1838–1849 елларда Урта Азиягә китеп, Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләрендә укый. Биредә хөкем сөргән иске тәртипләрдән, фикер торгынлыгыннан риза булмыйча, ул күбрәк вакыт кыйммәтле кульязмаларга бай китапханәләрдә мөстәкыйль шөгыльләнә. Ул заманның алдынгы карашлы галимнәре белән аралаша, әл-Фәраби, Әбүгалисина, Ибне Рөшд, Фирдәүси, Сәгъди, Хәйям, Нәвои һәм Көнчыгышның башка мәшһүр галимнәре, фикер ияләренең әсәрләрен өйрәнә. Мәрҗани ныклап гарәп һәм фарсы телләрен үзләштерә, үзенең күп кенә хезмәтләрен гарәп телендә яза.

Туган ягына кайтып, өч ай үткәч, 1850 елда Казан шәһәренең беренче мәчетенә имам һәм аның каршындагы мәдрәсәгә мөдәррис итеп билгеләнә. Монда ул баштанаяк педагогик һәм фәнни эшкә чума, мәдрәсәдә укытуны тәртипкә салу буенча яңалыклар кертә башлый.

1867–1868 елларда Идел буе һәм Урал алды мөселманнарының Диния нәзарәте Мәрҗанине Казан шәһәренең ахуны һәм мөхтәсибе итеп билгели. Әлеге күренеш аның эшчәнлеген мөселман җитәкчеләренең тануын раслый.

Тора-бара Мәрҗанинең исеме Казаннан еракларда да билгеле була: 1870 елда аның китабы басылып чыга. Ул авторга үз ватанында гына түгел, мөселман Көнчыгышында да киң танылу китерә.

XIX йөзнең 70–80 нче еллары – Мәрҗанинең рус мәдәнияте, Казан университетының Көнчыгышны өйрәнүче галимнәре белән якыннан танышу чоры. Мәрҗани, мөселман галимнәреннән беренче буларак, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә әгъза итеп сайлана, аның эшчәнлегендә актив катнаша.

1876–1884 елларда Ш.Мәрҗани Казанда Татар укытучылар мәктәбендә дин сабагы укыта.

XIX йөзнең 80 нче елларында Ш.Мәрҗани гарәп телендә «Вафиййәтел-әслаф вә тәхиййәтел-әхләф» («Элгәрләрнең некрологлары һәм аларның киләчәк буыннарга бүләге») исемле җиде томлык хезмәтен яза. Әлеге энциклопедик характердагы биографик сүзлектә мөселман Көнчыгышының 6057 галиме, әдибе, фәлсәфәчесе, иҗтимагый-сәяси эшлеклесенең тәрҗемәи хәлләре урын алган.

«Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») хезмәтенең беренче кисәге – 1885, 1897 елларда, икенчесе 1900 елда дөнья күрә.

Утыздан артык хезмәт язган Ш.Мәрҗанинең исеме Көнчыгышта гына түгел, ә Европада һәм Америкада да билгеле була.

Шиһабетдин Мәрҗани 1889 елның 27 апрелендә вафат була.

Просветитель, богослов, историк, философ, востоковед, педагог Шигабутдин Багаутдинович Марджани родился 16 января 1818 г. в деревне Ябынчы Казанского уезда Казанской губернии (ныне Атнинский район Татарстана) в семье духовного лица. Начальное образование получает в медресе своего отца в деревне Ташкичу. Юный Шигабутдин самостоятельно занимается в домашней библиотеке. С 17 лет он начинает помогать отцу в обучении его воспитанников.

В 1838–1849 гг. учится в медресе Бухары и Самарканда. Будучи неудовлетворенным устаревшими порядками, царившими там, духовным застоем, Ш.Марджани много времени проводит за чтением в богатых ценными рукописями библиотеках. Он общается с передовыми учеными того времени, изучает произведения аль-Фараби, Ибн Сины, Ибн Рушда, Фирдоуси, Саади, Хайяма, Навои и др. Ш.Марджани основательно изучает арабский и персидский языки, многие его произведения будут написаны на арабском языке.

В 1850 г., спустя три месяца после его возвращения на родину, Ш.Марджани назначается имамом первой Казанской мечети и мударрисом медресе при ней. Здесь он с головой уходит в педагогическую и научную работу, предпринимает меры по упорядочению работы медресе.

В 1867–1868 гг. Духовное собрание мусульман Поволжья и Приуралья назначает Марджани на должность ахуна и мухтасиба Казани, что свидетельствует о признании его деятельности мусульманскими руководителями.

Со временем имя Марджани становится известным далеко за пределами Казани: в 1870 г. выходит его книга, принесшая автору широкую известность не только на родине, но и на мусульманском Востоке.

70–80 гг. XIX века – это время близкого знакомства Марджани с русской культурой, учеными-востоковедами Казанского университета. Марджани первым из мусульманских ученых избирается в Общество археологии, истории и этнографии при Казанском университете, активно участвует в его деятельности.

В 1876–1884 гг. Ш.Марджани преподает вероучение в Казанской татарской учительской школе.

В 80-х годах XIX века Ш.Марджани пишет на арабском языке свой труд в семи томах «Достаточное о предках и приветствие потомкам». В этот биографический словарь энциклопедического характера вошли биографии

6057 ученых, писателей, философов, общественно-политических деятелей мусульманского Востока.

Первая часть его сочинения «Полезные сведения о Казани и Болгаре» увидела свет в 1885, 1897 годах, вторая – в 1900 году.

Имя Шигабуддина Марджани – автора свыше тридцати трудов – было известно не только на Востоке, но и в Европе и Америке.

Ш.Марджани умер 27 апреля 1889 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар: Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 145 б.

Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – 704 б. – («Шәхесләребез» сер.)

Шиһабетдин Мәрҗани. – Әлмәт: Рухият, 1998. – 175 б.

Мәрҗани: тарих һәм хәзерге заман: Халыкара фәнни конф. материаллары = Ш.Марджани: наследие и современность: материалы международ. науч. конф. – Казань, 1998. – 196 с.

Шиһабетдин Мәрҗани: мәкаләләр җыентыгы /[төз. Х.Хисмәтуллин]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – 80 б.

Шәех Л. Шиһабетдин Мәрҗани //Кырык татар = Сорок татар = The Forty Tatars. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – Б. 203-211. – Тексты на татар., рус. и англ. яз.

Юзиев А. Шиһабетдин Мәрҗани //Татар зыялылары: тарихи портретлар. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 40-49.

Абдуллин Я. Шиһабетдин Мәрҗани //Казан утлары. – 1998. – № 1. – Б. 127-136.

Каран Әхмәт Л. Шиһабетдин Мәрҗани тормышы һәм әсәрләре //Әдәби мирас: (дүртенче кит.). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – Б. 41-91.

Госманов М. Гасырдан-гасырга. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 488 б. – Шиһабетдин Мәрҗани һәм тарихи чыганакларны өйрәнү. – Б. 155-161.

Хәсәнов М. Олуг галим, мәгърифәтче //Мәгариф. – 1998. – № 3. – Б. 2-5.

Мәрҗани китапханәсе: фәнни-библиогр. җыентык /[төз., кереш сүз язучы Р.Ф.Мәрданов]. – Казан: Милли китап, 2004. – 122 б. – Рез. рус һәм инглиз тел.

Мәрданов Р. Шиһабетдин Мәрҗани мирасына бәйле кайбер яңа табышлар //Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2000. – № 3/4. – Б. 184-185.

Исламов Ф. Әдәбиятта, сәнгатьтә Шиһабетдин Мәрҗани образы //Мәйдан. – 2009. – № 2. – Б. 147-152.

Биктимерова Т. Кояш каралмас, алтын тутыкмас: [Ш.Мәрҗани исеме белән бәйләнгән истәлекле урыннар тур.] //Мәд. җомга. – 1998. – 18 сент. – Б. 8.

Асылкаева Н. «Бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт»: [Ш.Мәрҗанинең мирасына һәм эшчәнлегенә багышланган әдәбият белән эшләү өчен китапханәчеләргә методик киңәшләр] //Китапханә хәб. = Библиотечный вест. – 1997. – № 2. – Б.41-43.

Марджани: ученый, мыслитель, просветитель. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – 191 с.

Юсупов М. Шигабутдин Марджани. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – 271 с.: ил.

Очерки Марджани о восточных народах. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2003. – 175 с.

Юзеев А. Метеор веры: биограф. повесть о Ш. Марджани. – Н.Новгород: Изд-во НИМ «Махинур», 2005. – 140 с.

Юзеев А.Н. Татарская философская мысль конца XVIII–XIX вв. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2001. – 192 с. – Религиозно-реформаторские аспекты мировоззрения Ш.Марджани. – С. 103-111; Татарская религиозная философия конца XVIII–XIX вв. – С.122-135.

Юзеев А. Шихаб ад-дин Марджани //Духовная культура и татарская интеллигенция: исторические портреты. – Казань: Магариф, 2000. – С. 26-34.

Ибрагим Т.К., Султанов Ф.М., Юзеев А.Н. Татарская религиозно-философская мысль в общемусульманском контексте. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – 239 с. – Религиозно-философские взгляды Ш.Марджани. – С.125-137.

Ислам на европейском Востоке: энцикл. слов. – Казань: Магариф, 2004. – 383 с. – Ш.Марджани. – С.186-189.

Автобиография Шихабаддина Марджани /[вступ. ст. и док. к публ. подгот. А.Юзеев] //Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2000. – № 3/4. – С.114-122.

Юзеев А. Марджани – первый идеолог татарской нации //Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2000. – № 1/2. – С. 183-196.

Юзеев А. Путевые заметки Марджани //Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2008. – № 1. – С. 158-160.

Абдуллин Я. Основоположник научной истории татар Шигабутдин Марджани //Казань. – 2001. – № 12. – С. 23.

Халидов А. Начало научной истории татар: концепция исторического самосознания у Марджани //Казань. – 1999. – № 5-6. – С. 61-62.

Ахунов А. Шигабутдин Марджани. Быть великим непросто //Идель. – 2008. – № 6. – С. 26-30.

Ахунов А. Книги Марджани //Идель. – 2008. – № 11. – С. 52-53.

Юлай Шамиль-оглы. Шигабуддин Марджани и образ Золотой Орды /[пер. с англ. Д.Исхакова] //Татарстан. – 1991. – № 10. – С. 21-29. То же в парал. изд. на татар. яз. – С. 48-57.

Салихов Р. Творец татарской истории //Время и деньги. – 2003. – 15 янв.

**30 гыйнвар** **Карл Людвигович Мюфке**
**30 января** **1868–1933**
**тууына 150 ел**
**150 лет со дня рождения**

Архитектор Карл Людвигович Мюфке 1868 елның 30 гыйнварында Воронеж шәһәрендә аптекарь-провизор гаиләсендә туа. Башлангыч белемне гимназиядә алгач, Петербург сәнгать академиясенең архитектура бүлегенә укырга керә. 1893 елда ул Академия каршында оештырылган Югары сәнгать училищесына тыңлаучы булып күчә. Өч елдан ул училищены уңышлы тәмамлый. Белемен күтәрү һәм классик архитектураны өйрәнү өчен аны Австрия, Германия, Италия һәм Франциягә командировкага җибәрәләр.

Казан сәнгать мәктәбенең архитектура классы ачарга карар кылган педагогик советы К.Мюфкены укытучы итеп чакыра һәм ул 1987 елның 1 гыйнварында бу вазыйфага билгеләнә. Карл Людвигович Казанга килә.

Сәнгать мәктәбендә К.Мюфке архитектура бүлеге оештыра һәм аның җитәкчесе була, архитектура тарихы, перспектива һәм шәүлә (карамчык), төзелеш сәнгате фәннәрен укыта, архитектур проектлаштыру, сызым, рәсем сәнгате буенча дәресләр алып бара. Бер үк вакытта, 1898–1899 елларда, ул – Казан промышленность (сәнәгать) училищесында техник сурәтләр һәм төзелеш сәнгате укытучысы. Шушы ук вакытта педсовет аны Сәнгать мәктәбенең мөдире итеп сайлый.

1900–1902 елларда К.Мюфке – Казан университеты архитекторы.

1909 елдан ул – Саратов университетының төзүче архитекторы. 1912 елда даими яшәргә Саратовка күчеп китә. 1920 елдан Саратов политехник университетының гражданнар архитектурасы һәм архитектура формалары, Саратов гамәли-инженерлар институтының архитектура һәм архитектур проектлаштыру профессоры.

К.Л.Мюфке – Казанда XIX–XX йөзләр чикләрендә иң күренекле архитектор. Ул яңа рус, яңа классицизм һәм модерн стильләрендә эшли. К.Мюфке проектлары буенча 1900–1905 елларда Казан сәнгать мәктәбе бинасы, 1902–1904 елларда Казан университеты төп бинасының көнбатыш канаты, 1904–1908 елларда Зинаида Ушкова йорты (хәзер Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең төп бинасы), 1907–1908 дә Мюфке йорты, 1909–1930 елларда Саратов университеты комплексы һәм Агафоновка авылында университетның клиник шәһәрчеге төзелә, 1902–1912 елларда Казан университетының төп бинасы үзгәртеп корыла.

К.Л.Мюфке 1933 елның 13 февралендә Саратов шәһәрендә вафат була.

Архитектор Карл Людвигович Мюфке родился 30 января 1868 года в Воронеже в семье аптекаря-провизора. Первоначальное образование получает в местной гимназии, после которой поступает в Петербургскую Академию художеств на архитектурное отделение. В 1893 году он

переводится слушателем созданного при ней Высшего художественного училища. Через три года с отличием заканчивает училище. Посещает Австрию, Германию, Италию и Францию с целью изучения классического архитектурного наследия.

Решением педагогического Совета при Казанской художественной школе открывается класс архитектуры, куда в качестве преподавателя приглашается К.Мюфке. С 1 января 1897 года он утверждается в этой должности и переезжает в Казань.

В Художественной школе К.Мюфке организует архитектурное отделение и становится его руководителем, преподает историю архитектуры, теорию перспективы и теней, строительное искусство, ведет занятия по архитектурному проектированию, черчению, рисованию, живописи. Одновременно, в 1898–1899 гг. он преподает техническое рисование и строительного искусства в Казанском промышленном училище. В это же время педсовет избирает его заведующим Художественной школой.

В 1900–1902 гг. К.Мюфке – архитектор Казанского университета.

С 1909 г. – архитектор университета города Саратова, куда в 1912 году переехал на постоянное местожительство. С 1920 года – профессор гражданской архитектуры и архитектурных форм Саратовского политехнического института, профессор архитектуры и архитектурного проектирования Саратовского инженерно-практического института.

К.Л.Мюфке – выдающийся казанский зодчий рубежа XIX–XX веков. Он работал в неорусском стиле, в стилях неоклассицизма и модерна. По проектам Карла Людвиговича построены: в 1900–1905 гг. – здание Казанской художественной школы, в 1902–1904 гг. – западное крыло главного здания Казанского университета, в 1904–1908 гг. – Дом Зинаиды Ушковой (в настоящее время – главное здание Национальной библиотеки Республики Татарстан), 1907–1908 гг.

– Дом Мюфке в Казани, в 1909–1930 гг. – комплекс Саратовского университета и университетского клинического городка в поселке Агафоновка, в 1902–1912 гг. – перестроено главное здание Казанского университета.

К.Л.Мюфке умер 13 февраля 1933 года в городе Саратове.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

Саначин С.П. Исследования по истории Казанского края, преимущественно Казани: сб. ст. – Казань: Kazan-Казань, 2015. – 432 с.: ил. – Карл Мюфке, его жизнь и архитектура. – С. 281-295; Еще о Карле Мюфке. – С. 343-354.

Саначин С. Карл Мюфке, его жизнь и архитектура //Казань. – 1996. – № 9-12. – С. 92-98.

Осятинский А.П. Архитектурный ансамбль К.Л.Мюфке в Саратове. – Саратов: Изд-во Саратов. ун-та, 1984. – 56 с. – Биография. – С. 7-12.

Петров Б. Архитектор Саратовского университета: [К.Л.Мюфке] //Годы и люди. – Саратов: Приволжск. кн. изд-во, 1983. – С. 65-73.

Ключевская Е. Карл Мюфке: «Меня постоянно тянет в Казань...» //Респ. Татарстан. – 1995. – 18 марта.

Григорьев А. Карл Мюфке, построивший русский терем //Казанские ведомости. – 1993. – 15 апр.

Глазырина Ю.И. Вклад архитектора К.Л.Мюфке в реконструкцию комплекса Казанского университета в начале XX века //Известия Казанского архитектурно-строительного университета. – 2011. – № 4. – С. 23-31.

Саначин С. Карл Мюфке, аның тормышы һәм архитектурасы //Казан. – 1996. – № 9-12. – Б. 92-98.

**12 март** — **«Ватаным Татарстан» газетасы**
**12 марта** — **газета «Ватаным Татарстан»**

**1918**

**беренче саны чыгуга 100 ел**
**100 лет со дня выхода первого номера**

Көндәлек иҗтимагый-сәяси «Ватаным Татарстан» газетасы – татар матбугатының иң абруйлы басмаларыннан берсе. Ул 1918 елның 12 мартыннан Казанда татар телендә нәшер ителә башлый. Исеме үзгәреп тора: 1918–1920 елларда «Эш», 1920–1922 дә «Татарстан хәбәрләре», 1922–1924 тә «Татарстан», 1924–1951 дә «Кызыл Татарстан», 1951–1960 та «Совет Татарстаны», 1960–1992 дә «Социалистик Татарстан», 1992 елның февраленнән – «Ватаным Татарстан». Газетаның оештыручылары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, редакция коллективы. Газетаның мөхәррирләре: Ш.Әхмәдиев (1918), Х.Урманов (1918), В.Шәфигуллин (1918–1921), Ф.Бурнаш (1921–1924), Ф.Сәйфи-Казанлы (1924–1925), Г.Нигъмәти (1926–1927), С.Борһан (1928–1929), И.Еникеев (1930–1931, 1937), Г.Ризванов (1932–1936), А.Дәүләтьяров (1937), Х.Габдрахманов, С.Атнагулов (1938–1940), И.Н.Үзбәков (1941–1950), Г.Рябков (1950–1960), Ш.Хамматов (1960–1983), Р.Сабиров (1983–1990), М.Әһлиуллин (1990–1996), Г.Шәмсетдинов (1996–2003), 2003 тән М.Сәфәров.

Газетада Г.Камал, Ф.Әмирхан, Ш.Усманов, К.Тинчурин, Һ.Такташ, Х.Туфан, Г.Кутуй, А.Шамов, М.Әмир, И.Гази, Ф.Хөсни, Ш.Мөдәррис, Н.Арсланов һ.б. күренекле татар язучылары эшли.

Казан мех комбинатында (1934), Чистай (1935), Минзәлә, Әлмәт (1947), Калинин (1949) районнарында газетаның күчмә редакцияләре була. Төрле елларда газета кушымталар бастыра. «Кызыл командир» (1926, «Кызылармеец» газетасы белән бергә); «Сыйфат өчен» (1933), «Волга буе спартакиадасы» (1934); «Стахановчылык листовкасы» (1936); «Кызыл Татарстан» листовкасы» (1936); «Совет Татарстаны»ның махсус чыгарылышы» (1952). 1985–2003 тә «Әдәби җомга», 1999–2003 тә «Серле сандык», 2004 тән «Сәламәтлек», «Яшелчә», «Гаилә», 2005 тән «Яшел бишек», «Ышаныч һәм иминлек» даими кушымталары чыгарыла.

«Ватаным Татарстан» республика һәм илнең иҗтимагый, икътисади һәм мәдәни тормышындагы мөһим вакыйгаларны даими яктыртып бара, укучыларга юрист киңәшләре бирә. Татарстан журналистларының күпчелеге өчен осталык мәктәбе булып тора.

Газета татар телендә Татарстан Президенты Указларын, ТР Дәүләт Советы кабул иткән законнарны, ТР Министрлар Кабинеты карарларын беренче булып бастыра. Республиканың әйдәп баручы газетасы буларак, «Ватаным Татарстан» Татарстаннан читтә яшәүче татарлар тормышын да киң яктырта.

1968 елда газета Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Ежедневная общетатарская общественно-политическая газета «Ватаным Татарстан» («Родина моя Татарстан») является ведущим периодическим изданием Татарстана на татарском языке. Издается с 12 марта 1918 года в Казани. Название менялось: в 1918–1920 гг. – «Эш», в 1920–1922 гг. – «Татарстан хәбәрләре» («Известия Татарстана»), в 1922–1924 – «Татарстан», в 1924–1951 – «Кызыл Татарстан» («Красный Татарстан»), в 1951–1960 – «Совет Татарстаны» («Советский Татарстан»), в 1960–1992 – «Социалистик Татарстан» («Социалистический Татарстан»), с февраля 1992 г. – «Ватаным Татарстан». Учредителями являются Государственный Совет РТ, Кабинет Министров РТ, коллектив редакции. Редакторы: Ш.Ахмадеев (1918), Х.Урманов (1918), В.Шафигуллин (1918–1921), Ф.Бурнаш (1921–1924), Ф.Сайфи-Казанлы (1924–1925), Г.Нигъмати (1926–1927), С.Бурган (1928–1929), И.Еникеев (1930–1931, 1937), Г.Ризванов (1932–1936), А.Давлетьяров (1937), Х.Габдрахманов, С.Атнагулов (1938–1940), И.Н.Узбеков (1941–1950), Г.Рябков (1950–1960), Ш.Хамматов (1960–1983), Р.Сабиров (1983–1990), М.Аглиуллин (1990–1996), Г.Шамсутдинов (1996–2003), с 2003 года М.Сафаров.

В газете работали: Г.Камал, Ф.Амирхан, Ш.Усманов, К.Тинчурин, Х.Такташ, Х.Туфан, Г.Кутуй, А.Шамов, М.Амир, И.Гази, Ф.Хусни, Ш.Мударрис, Н.Арсланов и многие другие видные татарские писатели.

Передвижные редакции газеты работали на Казанском меховом комбинате (1934), в Чистопольском (1935), Мензелинском, Альметьевском (1947), Калининском (1949) районах. Газета выпускалась с приложениями: «Кызыл командир» («Красный командир», 1926), совместно с газетой «Кызылармеец» («Красноармеец»); «Сыйфат өчен» («За качество», 1933); «Волга буе спартакиадасы» («Спартакиада Поволжья», 1934); «Стахановчылык листовкасы» («Листовка стахановца», 1936); «Кызыл Татарстан» листовкасы» («Листовка «Кызыл Татарстана», 1946); «Совет Татарстанының» махсус чыгарылышы» («Специальный выпуск газеты «Совет Татарстаны», 1952). С 1995 года выходит пятничное литературное приложение, с 1999 – приложение «Серле сандык» («Волшебный сундучок»), с 2004 – «Сәламәтлек» («Здоровье»), «Яшелчә» («Овощи»), «Гаилә» («Семья»), с 2005 – «Яшел бишек» («Зеленая колыбель»), «Ышаныч һәм иминлек» («Доверие и безопасность»).

«Ватаным Татарстан» освещает важнейшие события общественной и культурной жизни республики и страны, является школой для многих татарских журналистов.

Газета первой на татарском языке публикует Указы Президента РТ, законы, принятые Государственном Советом РТ, постановления Кабинета Министров РТ. Оставаясь ведущей республиканской газетой, «Ватаным Татарстан» освещает также и жизнь татар, проживающих за пределами республики.

В 1968 году газета награждается орденом Трудового Красного Знамени.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

Һич онытасым юк...: [«Ватаным Татарстан» газетасының 95 еллыгына карата]. – Казан, 2013. – 352 б.: фото.

Сәфәров М. «Хөкүмәт басмасы сары басма булырга тиеш түгел» //Татарстан. – 2008. – № 2. – Б. 40-42.

Фәйзуллина Л. 95 яшь – ул ничек була? //Ватаным Татарстан. – 2013. – 21 май.

Хамматов Ш. Газета һәм әдәбият дуслыгы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 184 б.

Абдуллин М. Иртәдә генә торам, юлга чыгам; Әхмәтҗанова М. Соңгы сәгатьтә; Вәли-Әхмәт Х. Йөрәк – Каф таулары түгел; Ибраһим Х. Беренче гәҗитем; Мостафин М. Гомер агышлары; Сәфәров М. Без үзгәрдек. Ә дөнья: мәкаләләр //Ватаным Татарстан. – 2013. – 12 март.

Ташка язган югалмый //Ватаным Татарстан. – 2008. – 12 март.

Шамсутдинов Г. Газета всероссийского значения на татарском языке //Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1999. – № 1/2. – С. 173-175.

Опираясь на опыт, шагают в будущее: газета «Ватаным Татарстан» отметила свое 95 летие //Респ. Татарстан. – 2013. – 18 мая.

**24 март**
**24 марта**

**Мөхәммәт Гали**
**Мухаммед Гали**
**1893–1952**
**тууына 125 ел**
**125 лет со дня рождения**

Мөхәммәт Гали (Мөхәммәт Вәли улы Галиев) үзенең хикәяләре, драма әсәрләре һәм әдәби гыйльми хезмәтләре белән XX йөз татар әдәбияты тарихында үзенә бер аерым урын алып тора. Ул 1893 елның 24 мартында Казан губернасы Лаеш өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы) Олы Елга авылында мулла гаиләсендә туа. Башта авыл мәктәбендә, 1903–1910 елларда Сатыш мәдрәсәсендә, аннары Казанның Күл буе («Касыймия») һәм 1912–1915 елларда Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Укуын ташлап, төрле эшләрдә эшли. Ул солдатка алына, 1916 елның февралендә фронтка озатыла, беренче Бөтендөнья сугышында катнаша.

1917 елның сентябренә туган авылына кайта, укытучы булып эшли.

1919 елның башында Казанга килә, «Кызыл Армия», «Эшче», «Татарстан хәбәрләре», соңрак «Безнең байрак», «Крестьян газетасы» редакцияләрендә эшли.

1931 елда М.Гали Казан университетының география факультетына укырга керә. Аны тәмамлагач, Казан педагогия институтында укыта.

1945 елның ахырыннан ул СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында гыйльми хезмәткәр һәм кулъязмалар бүлегенең мөдире булып эшли.

М.Галинең «Авыл тормышы» исемле хикәясе 1911 елда Казандагы «Йолдыз» газетасында басылып чыга. 1914–1915 елларда «Аң» журналы битләрендә бер-бер артлы бер төркем хикәяләрен бастыра. Әсәрләрендә революциягә кадәрге авыл тормышын һәм 1920–1930 нчы елларда барган социаль үзгәрешләрне тасвирлый.

1930 нчы елларда М.Гали драма жанрында көчен сынап карый. Аның «Печәнчеләр, яки Бәхет эзләгәндә» (1936), «Имана» (1939) дигән пьесалары бар. Х.Уразиков белән бергә язылган «Каюм Насыйри» (1945) дигән пьесасы Татар академия театрында куела һәм берничә ел сәхнәдә уйнала. Ул – Каюм Насыйри турында язылып бетмичә калган роман авторы.

М.Гали – татар язучылары арасында әдәбият тарихын өйрәнүгә иң күп көч куйган язучыларның берсе. Татар әдәбияты тарихының аерым мәсьәләләренә, әдипләрнең тормыш һәм иҗатларына багышланган гыйльми хезмәтләре бар. Аның «Г.Камал» исемле монографиясе, Тукай, Г.Мәхмүдов, И.Хәлфин, Акмулла, С.Рәмиев турындагы һ.б. күләмле мәкаләләре фактик материалга бай булулары белән аерылып торалар.

Ул тәрҗемә китаплар авторы буларак та билгеле. И.С.Тургеневның «Аучы язмалары» (1930), Ж.Вернның «Су астында 80 000 километр» (1938) әсәрләрен, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов хикәяләрен тәрҗемә итә.

М.Гали 1952 елның 6 маенда вафат була.

Мухаммед Гали (Мухаммед Валиевич Галиев) – автор рассказов, драматических произведений и литературно-научных трудов – занимает особое место в истории татарской литературы XX века. Он родился 24 марта 1893 года в деревне Большая Елга Лаишевского уезда Казанской губернии (ныне Рыбно-Слободский район Республики Татарстан) в семье муллы. Начальное образование получил в деревне, в 1903–1910 гг. учился в медресе деревни Сатыш, потом в медресе «Касимия» в Казани, в 1912–1915 гг. – в Оренбурге в медресе «Хусаиния».

Бросив учебу, работает в разных местах. Его мобилизуют в царскую армию, в феврале 1916 года отправляют на фронт. Участник Первой мировой войны.

В сентябре 1917 года М.Гали возвращается в родную деревню, работает учителем.

В начале 1919 года он приезжает в Казань, работает в редакциях газет «Кызыл Армия» («Красная Армия»), «Эшче», («Рабочий»), «Татарстан хәбәрләре» («Известия Татарстана»), позже «Безнең байрак» («Наше знамя»), «Крестьян газетасы» («Газета крестьянина»).

В 1931 году М.Гали поступает на географический факультет Казанского университета, после окончания которого преподает в Казанском педагогическом институте.

С конца 1945 года работает научным сотрудником и заведующим отделом рукописей в Институте языка, литературы и истории Казанского филиала Академии наук СССР.

Литературная деятельность М.Гали началась в 1911 году. Его первый рассказ «Авыл тормышы» («Деревенская жизнь») был опубликован в газете «Йолдыз» в Казани. В 1914–1915 гг. на страницах журнала «Аң» публикуются его рассказы, многие из которых посвящены жизни дореволюционной деревни, социальным изменениям в селе в 1920–1930-е годы.

В 1930-е годы М.Гали создаёт и драматические произведения – пьесы «Печәнчеләр, яки Бәхет эзләгәндә» («Косари, или В поисках счастья», 1936); «Имана» («Подушная», 1939) и др. Пьеса «Каюм Насыри», написанная совместно с Х.Уразиковым, была поставлена и на протяжении нескольких лет шла на сцене Татарского академического театра.

Мухаммед Гали – татарский писатель, внесший большой вклад в изучение истории литературы, автор научных трудов, посвященных отдельным вопросам истории татарской литературы, жизни и творчеству татарских писателей. Его монография «Г.Камал», исследования творчества

Г.Тукая, Г.Махмудова, И.Хальфина, Акмуллы, С.Рамиева и других отличаются богатством фактического материала.

В последние годы жизни писатель работает над большим романом о Каюме Насыри, завершить который ему не удалось.

Он известен также как переводчик: перевел на татарский язык «Записки охотника» И.С.Тургенева («Аучы язмалары», 1936), «80000 км под водой» Ж.Верна («Су астында 80000 километр», 1938), рассказы Л.Н.Толстого, А.П.Чехова.

М.Гали умер 16 мая 1952 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

Гали М. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – 316 б.: портр.

Гали М. Сайланма әсәрләр /[М.Гайнуллин кереш сүзе белән; төз. Х.Мөхәммәтов]. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 372 б.

Гали М. Шагыйрь баскан эзләрдән. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – 48 б.

Гали М. Каюмның балачагы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – 80 б.

Әдипләребез: биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т.1. /[төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 755 б. – Мөхәммәт Гали. – Б. 322-324.

Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Мөхәммәт Гали. – Б. 103-105.

Гайнуллин М. Татар әдипләре: (иҗат портретлары). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 280 б. – Мөхәммәт Гали. – Б. 230-240.

Әмирхан Р. Тыйнак талант //Татарстан. – 1993. – № 3. – Б. 49-55; № 4. – Б. 50-56.

Рәмиев З. Талантлы язучы, күренекле галим //Казан утлары. – 1993. – № 3. – Б. 165-168.

Галиева Р. Мөхәммәт Гали бездә эшләгән: [М.Гали 1925 елда Оренбургтан Казанга килеп «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә эшли] //Ватаным Татарстан. – 2017. – 25 окт.

Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. справочник. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Мухамед Гали. – С. 116-117.

Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика начала XX века. – 2-е изд., доп. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. – 352 с. – О Мухамеде Гали. – С. 238-240.

**28 март** **Максим Горький**
**28 марта** **1868–1936**
**тууына 150 ел**
**150 лет со дня рождения**

Язучы, җәмәгать эшлеклесе Максим Горький (Алексей Максимович Горький) 1868 елның 28 мартында Түбән Новгород шәһәрендә туа. 1884 елның августында ул университетка укырга керү максаты белән Казанга килә, ләкин башлангыч белем белән бу мөмкин булмый.

Алексей елга портында йөк ташучы, генерал Корнэ хатынында бакча караучы һәм ишегалды себерүче, кибетче А.С.Деренковның пекарнясында ярдәмче булып эшли. 1885 елда ул народниклар түгәрәкләренә йөри, яшерен әдәбият укый башлый. 1888 елның мартында Алексей Казаннан китә, шул елның июненнән сентябренә кадәр Иделдәге Красновидово авылында (хәзерге Кама Тамагы районы) яши.

Казанда узган еллары М.Горькийның берничә әсәрендә чагыла: «Бервакыт көз көнендә» («Однажды осенью»), «Каптырма мәсьәләсе» («Дело с застежками»), «Акулина әби» («Бабушка Акулина», барысы да 1895 елда язылган), «Коновалов» (1896), «Элекке кешеләр» («Бывшие люди», 1897), «Хуҗа» («Хозяин», 1913), «Минем язарга өйрәнүем» («О том, как я учился писать», 1919) һ.б.

Казанда яшәгән елларын соңрак А.М.Горький үзенең шәхес буларак формалашу чоры дип танып: «Физик яктан мин Түбән Новгородта, рухи яктан Казанда тудым. Казан – минем иң яраткан «университетларымның» берсе», – дип яза.

1928 елда А.М.Горький Казанга килә һәм шуннан башлап татар язучылары – К.Нәҗми, Г.Кутуй, Г.Минский, Ш.Усманов, Г.Толымбайский һ.б. белән ике арада тыгыз дуслык урнаша.

А.М.Горький 1936 елның 18 июнендә Мәскәүдә вафат була.

Язучы әсәрләренең күбесе татар теленә тәрҗемә ителгән. Бу эш белән күренекле язучылар С.Әдһәмова, Г.Камал, Ш.Камал, А.Шамов, И.Гази, М.Әмир, Г.Кутуй шөгыльләнгән.

1940 елдан Казанда А.М.Горькийның әдәби-мемориаль музее, 1950 елдан Крсновидово авылындагы музее эшли. 1949 елда Казанның Вахитов районында М.Горькийның музей-йорты урнашкан урамга, Үзәк мәдәният һәм ял паркына аның исеме бирелә.

Писатель, общественный деятель Максим Горький (Алексей Максимович Горький) родился 28 марта 1868 года в городе Нижний Новгород. В августе 1884 года он приезжает в Казань с целью поступить в университет, однако с его начальным образованием это оказалось невозможным.

Алексей работает грузчиком в порту, садовником и дворником у генеральши Корнэ, подручным пекаря в булочной А.С.Деренкова. В 1885 году становится участником народнических кружков, изучает нелегальную литературу. В марте 1888 года Алексей уезжает из Казани, с июня до сентября того же года живет в селе Красновидово (ныне Камско-Устьинской район) на Волге.

Казанский период жизни М.Горького отражается в ряде его произведений: «Однажды осенью», «Дело с застежками», «Бабушка Акулина», (все 1895 года), «Коновалов» (1896), «Бывшие люди», (1897), «Хозяин» (1913), «О том, как я учился писать», (1919) и др.

Характеризируя время, проведенное в Казани, как период своего становления, М.Горький впоследствии писал: «Физически я родился в Нижнем Новгороде, духовно – в Казани. Казань – любимейший из моих университетов».

В 1928 году М.Горький посещает Казань и с этого времени поддерживает тесную творческую связь с татарскими писателями: К.Наджми, А.Кутуем, Г.Минским, Ш.Усмановым, Г.Тулумбайским и др.

А.М.Горький умер 18 июня 1936 г. в Москве.

Большая часть произведений писателя переведена на татарский язык. Над переводами работали известные писатели: Г.Камал, Ш.Камал, А.Шамов, И.Гази, М.Амир, А.Кутуй и др.

С 1940 года в Казани работает литературно-мемориальный музей А.М.Горького, 1950 года – музей в селе Красновидово.

В 1949 г. имя писателя было присвоено одной из улиц Вахитовского района города Казани, на которой находится дом-музей М.Горького. Именем писателя назван Центральный парк культуры и отдыха.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

Горький М. Истәлекләр /рус теленнән М.Галиев, С.Әдһәмова тәрж. – Казан: Мәгариф–Вакыт, 2016. – 223 б.

Горький М. Сайланма әсәрләр: 6 томда. – Казан: Татгосиздат, 1947. –

Т. 1. /С.Әдһәмова тәрж.; кереш сүз язучы К.Нәҗми. – 1947. – 629 б.

Т. 2. – 1949. – 382 б.

Т. 3. /С.Әдһәмова тәрж. – 1950. – 313 б.

Т. 4. /М.Максуд тәрж. – 1951. – 390 б.

Т. 5. /С.Әдһәмова тәрж. – 1950. – 318 б.

Горький М. Хикәяләр: ике томда /төз. С.Әдһәмова; И.Гази, Ә.Исхак, Г.Хәбиб тәрж. – Казан: Татгосиздат. –

Т. 1. – 1958. – 375 б.

Т. 2. – 1959. – 480 б.

Горький М. Повестьлар, хикәяләр /С.Әдһәмова, Г.Хәбиб, Ф.Бурнаш тәрж. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – 471 б.

Гайнуллин М. Дуслыкта – көч: публицистик мәкаләләр, әдәби очерклар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. – 248 б. – Безнең Горький. – Б. 65-73.

Гайнуллин М. Горький һәм татар әдәбияты //Казан утлары. – 1984. – № 8. – Б. 4-12.

Мәһдиев М. Давыл хәбәрчесе – Иделдә: М.Горькийның тууына 120 ел //Казан утлары. – 1988. – № 3. – Б. 170-178.

Дәүләтшина В. Без Горькийны беләбезме?; Мирзина Ф. Ул безнең халыкны ярата иде //Татарстан хәб. – 1993. – 30 март.

Хәйри Х. Язучы һәм тормыш: (әдәбият теориясе, әдәби хәрәкәт мәсьәләләре). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 288 б. – М.Горький һәм социалистик реализм мәсьәләләре. – Б. 40-64.

Коновалова С.А. Духовная родина Максима Горького. Казань в судьбе писателя. – Kazan-Казань, 2007. – 200 с.

Максим Горький на рубеже XX-XXI веков: материалы Горьковских чтений 28-29 марта 2001 г. – Казань: Карпол, 2001. – 79 с.

Казань в жизни и творчестве А.М.Горького и Ф.И.Шаляпина: материалы науч. конф., посвящ. 1000-летию Казани и 65-летию Литературно-мемориального музея А.М.Горького, сост. в Казани в 2005 году, а также Шаляпинских чтений, прошедших 13 февраля 2006 года. – Казань: РИЦ «Школа», 2009. – 156 с.

Елизарова М.Н. Незабываемые годы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – 168 с. – Горький в Казани. – С. 78-112; Горький в Казани в 1928 году. – С. 112-134.

Климентовский В.А. Русские писатели в Татарии. – 3-е изд., перераб., доп. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 174 с. – А.М.Горький. – С. 107-122.

Андреева Л. Родники культуры: [о Ф.Шаляпине и А.М.Горьком] //Казань. – 1998. – № 4. – С. 10-13.

Белова Л. Друзья по ссылке: В.Г.Короленко и М.А.Ромась //Казань. – 1998. – № 4. – С. 20-21.

Давлетшина В. Традиция продолжается: Горький и татарская литература //Казань. – 1998. – № 4. – С. 22-25.

Каримова А. След «почерка души»: М.Горький и Г.Исхаки //Казань. – 1998. – № 4. – С. 26-27.

Гольдшмидт И. Фотография и времена //Казань. – 1998. – № 4. – С. 28-40.

Карпов И. Чем грозит место с краю: А.М.Горький и Е.Н.Чириков //Казань. – 1998. – № 4. – С. 49-50.

Ермакова И. «Как жаль, что тебя нет с нами…»: советские писатели о Горьком //Казань. – 1998. – № 4. – С. 51-53.

Барахов В. Максим Горький на пороге XXI столетия //Казань. – 1998. – № 4. – С. 62-68.

Елизарова-Томус Ю. Свет из прошлого //Казань. – 1998. – № 4. – С. 112-113.

**20 апрель** **Ибраһим Исхак улы Хәлфин**
**20 апреля** **Ибрагим Исхакович Хальфин**
**1778–1829**
**тууына 240 ел**
**240 лет со дня рождения**

Хәлфиннәр династиясе татар мәдәнияте һәм алдынгы иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдырган.

Күренекле галим, педагог, мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Исхак улы Хәлфин 1778 елның 20 апрелендә Казанның Иске Татар бистәсендә туа. Бабасы Сәгыйть Хәлфин – беренче «Татар теленең әлифбасы...» хезмәтен язып, 1778 елда Мәскәү университеты типографиясендә бастырып чыгарган шәхес. Бабасы да (16 ел), әтисе дә (15 ел) Казанның Беренче ирләр гимназиясендә татар теле укыталар, күп кенә дәүләт актларын татарчага тәрҗемә итәләр.

Хәзерлекле, татар, рус, төрек, гарәп, фарсы, латин телләрен камил үзләштергән Ибраһим Хәлфин бабасы һәм әтисе юлыннан китә, үзенең бөтен гомерен, белемен халкының телен, тарихын өйрәнүгә багышлый. 1800 елда, әтисенең вафатыннан соң, шул ук Беренче ирләр гимназиясендә татар теле укыта башлый.

Эзләнүчән галим, тел фәнен укытудагы яңа методларны файдаланып, 1804 елда «Татар теленең әлифбасы һәм этимологиясе» («Азбука и этимология татарского языка») дәреслеген төзи. Әлеге хезмәт шул вакыт өчен күрелмәгән зур тираж белән (1200 данә) Азия басмаханәсендә нәшер ителә һәм бик озак вакытлар Россия шәһәрләрендә татар сыйныфлары өчен төп дәреслек булып тора.

Ибраһим Хәлфиннең «Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения, преподаваемые в Императорской Казанской гимназии» («Казан гимназиясендә укытыла торган татар теле әлифбасы һәм грамматикасы, гарәби укылыш кагыйдәләре белән», 1809) хезмәте Россиядә генә түгел, Көнбатыш Европа илләре галимнәре арасында да билгеле була.

1812 елда Казан университетында татар теле укытыла башлый, укытучы итеп Ибраһим Хәлфин чакырыла. Ул бирелә шулай ук төрек һәм гарәп телләрен дә укыта. Гимназия белән бергә университетта да эшли башлагач, ул үзенең гыйльми педагогик эшчәнлеген тагын да киңрәк җәелдерә. Атаклы рус һәм чит ил галимнәре, профессорлары белән аралаша башлый. Университет галимнәренең фикерләре И.Хәлфиннең эшчәнлегенә, фәнни карашларына да йогынты ясый.

Галим үзе тапкан, матбугатка әзерләгән төрки-татар чыганакларын – «Дастане Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» (1819), Хива ханы Әбелгазый Баһадур ханның «Шәҗәрәи-төрк» (1820) китапларын нәшер итә.

И.Хәлфин 1802–1828 елларда Казан гимназиясе каршында ачылган Азия басмаханәсендә цензор булып эшли. Ул университет китапханәсенә

төрки-татар, гарәп һәм фарсы кулъязмаларын туплау юнәлешендә зур эш башкара.

Фән һәм мәгариф өлкәсендәге уңышлары өчен Ибраһим Хәлфин 1823 елда татарлардан беренче булып адъюнкт-профессор дәрәҗәсенә лаек була.

Ибраһим Хәлфин 1829 елның 14 гыйнварында кинәт вафат була.

И.Хәлфин үзеннән соң бай мирас калдыра. Бүген дә татар теле өлкәсендә эшләүче галимнәр кыйммәтле фәнни чыганак буларак аның хезмәтләренә таяналар, иҗатына югары бәя бирәләр.

Династия Хальфиных оставила неизгладимый след в истории татарской культуры и передовой общественной мысли.

Видный ученый, педагог, просветитель и общественный деятель Ибрагим Исхакович Хальфин родился 20 апреля 1778 года в Старо-Татарской слободе города Казани. Его дед Сагит Хальфин является автором первого в России букваря татарского языка («Азбуки татарского языка...»), который был издан в 1778 году в типографии Московского университета. И дед (16 лет), и отец (15 лет) преподавали татарский язык в Первой мужской гимназии Казани, переводили на татарский язык многие государственные акты.

Эрудированный, знающий татарский, русский, турецкий, арабский, персидский, латинский языки, Ибрагим Хальфин продолжает учительские и подвижнические традиции деда и отца, всю свою жизнь и знания посвящает просвещению своего народа. В 1800 году, после смерти отца, он в той же Первой мужской гимназии начинает преподавать татарский язык.

Ибрагим Хальфин, используя передовые для того времени педагогические приемы и методы обучения, в 1804 году создает «Азбуку и этимологию татарского языка». Этот труд был издан очень большим тиражом (1200 экз.) для того времени в Азиатской типографии и на протяжении целого ряда лет был основным учебным пособием по изучению татарского языка в городах России.

«Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения, преподаваемые в Императорской Казанской гимназии» (1809) известна не только в России, но и среди ученых Западной Европы.

В 1812 году в Казанском университете начинают преподавать татарский язык. И.Хальфина приглашают преподавателем. Помимо татарского, он обучает турецкому и арабскому языкам. Работая и в гимназии, и в университете, он расширяет свою научную и педагогическую деятельность, сотрудничает со знаменитыми русскими и зарубежными учеными, профессорами, которые влияют на научные взгляды И.Хальфина.

Ученый издает найденный им свод средневековых сказаний «Жизнь Джингис-хана и Аксак-Тимура» (1819) и подготавливает к выпуску книгу Абульгази Бахадур хана «Родословная тюрок». Эти труды И.Хальфина сделали его популярным среди российских и зарубежных востоковедов.

В 1802–1828 гг. И.Хальфин работает в должности цензора, выполняя роль редактора почти всех изданий типографии и переводчика в Азиатской типографии, открытой при Казанской гимназии.

И.Хальфин проявляет постоянную заботу о комплектовании университетской библиотеки различного рода редкими сочинениями и рукописями восточных авторов, учебными пособиями.

За успехи в области науки и образования Ибрагим Хальфин в 1823 году первым из татар был удостоен звания адъюнкт-профессора.

Ибрагим Хальфин умер 14 января 1829 года.

И.Хальфин оставил после себя богатое научное наследие, к которому и сегодня обращаются ученые-языковеды.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

Хаков В. Атаклы нәсел дәвамчысы //Мәдәни җомга. – 2008. – 27 июнь. – Б. 13.

Нуриева Ф.Ш. Беренче татар профессоры Ибраһим Хәлфин // TATARIKA. – 2014. – № 1(2). – Б. 226-229.

Михайлова С.М. Ибрагим Исхакович Хальфин. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – 40 с.

Михайлова С.М. Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья (1800–1861). – Казань: Изд-во Казан. ун-та,1972. – 228 с. – Просветитель Ибрагим Исхакович Хальфин. – С.105-161.

Мазитова Н.А. Изучение Ближнего и Среднего Востока в Казанском университете (первая половина XIX века). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1972. – 226 с. – Ибрагим Хальфин – первый адъюнкт восточной словесности Казанского университета. – С. 97-112.

Ахметгалиева Я.С. Грамматика татарского языка Ибрагима Хальфина // Сов. тюркология. – 1979. – № 6. – С. 23-30.

Nurieva F.Sh. The first tatar professor Ibrahim Khalfin // TATARIKA. – 2014. – № 1(2). – S. 224-226.

**3 июнь** **Флүс Латыйфи**
**3 июня** **Флюс Латыфи**
**1943–2010**
**тууына 75 ел**
**75 лет со дня рождения**

Язучы һәм публицист Флүс Фатыйх улы Латыйфи (Латыйпов) 1943 елның 3 июнендә Татарстан АССРның Мөслим районы Мөслим авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Урта белемне туган авылы мәктәбендә алганнан соң, ул Алабуга педагогия институтына укырга керә. Хәрби хезмәткә алынуы сәбәпле, укудан аерылып тора.

Ф.Латыйфи 1964–1969 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Студент елларында ук татар матбугаты белән хезмәттәшлек итә башлый. 1968 елдан ул – Татарстан радиосында хәбәрче, мөхәррир, яшьләр өчен тапшырулар редакциясе җитәкчесе.

1985 елның сентябреннән Ф.Латыйфи «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасына күчә, тагын бер елдан «Казан утлары» журналында эшли башлый: башта бүлек мөхәррире, аннары журналның җаваплы секретаре була. 1991 елда «Дөнья» дигән халыкара татар газетасында, «Татарстан хәбәрләре»ндә эшләп ала. 1993 елның көзендә ул «Татарстан» журналына баш мөхәррир урынбасары итеп билгеләнә. 1997 елда Ф.Латыйфи яңадан «Казан утлары» журналы редакциясенә кайта, журналның баш мөхәррир урынбасары булып эшли.

Ф.Латыйфи мәктәп елларында ук әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый. Аның беренче шигырьләре, хикәяләре район газетасында басыла, аннары республика матбугатында күренә.

Ф.Латыйфиның «Кырагай» исемле беренче хикәяләр җыентыгы 1988 елда басылып чыга һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәяләнә. Шул ук елда аның очерк һәм публицистик мәкаләләре тупланган «Вөҗданыңнан сора» дигән икенче китабы дөнья күрә. Әлеге җыентыктагы әсәрләре өчен язучы 1989 елда Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге премиясенә лаек була.

1993 елда аерым китап булып басылып чыккан «Хыянәт» романы язучыга аеруча киң популярлык китерә, аны татар прозаикларының алдынгы сафына бастыра.

Татар язучыларыннан беренче булып Ф.Латыйфи Румыниядә яшәүче татарларның халык авыз иҗатына мөрәҗәгать итеп, анда аеруча киң таралыш алган «Чура батыр» дастанын хәзерге татар әдәби теленә күчерә һәм аерым китап итеп бастырып чыгара.

Ф.Латыйфиның әдәби иҗаты актив җәмәгать эшләре белән дә тыгыз бәйләнгән. Ул татар яшьләренең «Сәләт» оешмасы белән хезмәттәшлек итә.

1993 елда Флүс Латыйфига Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә.

Ф.Латыйфи 2010 елның 16 февралендә вафат була.

Писатель и публицист Флюс Фатыхович Латыфи (Латыпов) родился 3 июня 1943 года в селе Муслюмово Муслюмовского района Татарской АССР в семье служащего. Окончив среднюю школу в родном селе, он поступает в Елабужский педагогический институт, со второго курса призывается в ряды Советский Армии.

В 1964–1969 гг. Ф.Латыфи учится на отделении татарского языка и литературы Казанского государственного университета. Со студенческих лет сотрудничает с татарской прессой. С 1968 года – на республиканском радио: работает в качестве репортера, редактора, возглавляет редакцию вещания для молодежи.

С сентября 1985 года Ф.Латыфи переходит в редакцию газеты «Социалистик Татарстан» (ныне «Ватаным Татарстан»), а через год – в редакцию журнала «Казан утлары» («Огни Казани»), где вначале работает редактором отдела, а позже ответственным секретарем. В 1991 году работает в международной татарской газете «Dөnja» («Планета»), позже – в рекдакции газеты «Татарстан хәбәрләре» («Известия Татарстана»). Осенью 1993 года утверждается на должность заместителя главного редактора журнала «Татарстан». В 1997 году Ф.Латыфи возвращается в редакцию журнала «Казан утлары» («Огни Казани»), работает заместителем редактора.

Литературным творчеством Ф.Латыфи начал заниматься еще в школьные годы. Первые его стихи и рассказы печатались в районной газете, позже стали появляться и в республиканской прессе. Первый сборник рассказов «Кырагай» («Дикарка») был издан в 1988 году и привлек внимание литературной общественности. В том же году вышла и вторая книга «Вөжданыңнан сора» («Испытание совести»). За эту книгу, включающую в себя очерки и публицистические стихи, Ф.Латыфи был удостоен премии им. Х.Ямашева Союза журналистов республики.

Романом «Хыянәт» («Измена»), изданной отдельной книгой в 1993 году, Ф.Латыфи заевовал широкую популярность среди читателей.

Ф.Латыфи первым среди татарских писателей обращается к устному народному творчеству румынских татар, переводит на литературный татарский язык широко популярный в Румынии исторический эпос «Чура Батыр».

Флюс Латыфи активно участвует в деятельности общественного движения татарской молодежи «Сәләт» («Одаренность»).

В 1993 году ему присвоено почетное звание «Заслуженный работник культуры Республики Татарстан».

Ф.Латыфи умер 16 февраля 2010 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

Латыйфи Ф. Сайланма әсәрләр: 3 томда. – Казан: Рухият, 2001.
Т.1: романнар. – 400 б.
Т.2: роман, фантастик повестьлар. – 400 б.
Т.3: повесть, хикәяләр, очерклар, мәкаләләр, эссе-парчалар. – 528 б.
Латыйфи Ф. Әманәт: хикәяләр. – Казан: Мәгариф, 2001. – 256 б.
Латыйфи Ф. Ишелеп төшкән бәхет: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 416 б. – (Кириллица һәм латин имлясында).

Латыфи Ф. Измена: роман /[пер. с татар. Ф.Фаязова]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. – 256 с.

Әдипләребез: биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т.2. /[төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б. – Флүс Латыйфи. – Б. 16-18.
Даутов Р. Балачак әдипләре: биобиблиогр. белешмәлек. 2 кит. = Писатели нашего детства: биобиблиогр. спр. 2 кн. – Казан: Мәгариф, 2004. – 286 б. – Флүс Латыйфи. – Б. 152-162. – Текст татар һәм рус телләрендә.
Заһидуллина Д. Яңа дулкында: (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңалыклар). – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б. – Тамырлары –тарихта. – Б. 27-49.
Заһидуллина Д. Милли реализм юлыннан //Казан утлары. – 2003. – № 6. – Б. 134-147.
Флүс Латыйфи //Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 291-292.
Сафин Ф. Иҗатка тугрылык //Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 305-306.
Баһаутдинов Ф. Без – Мөслим балалары. – Казан: Идел-Пресс, 2006. – Флүс Латыйфи. – Б. 444-447.
Акмал Н. Хыянәтсез яшьлек //Шәһри Казан. – 2003. – 30 май.

**23 июль** **Садри Максуди**
**23 июля** **1878–1957**
**туына 140 ел**
**140 лет со дня рождения**

Дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, татар милли хәрәкәте лидерларының берсе, хокук белгече, галим Садри Максуди (Садретдин Низаметдин улы Максудов) 1878 елның 23 июлендә (иске стиль белән) Казан губернасы Казан өязе Ташсу авылында (хәзер Татарстанның Биектау районы) мулла гаиләсендә туа,

Башлангыч белемне үз авылларында – әтисеннән ала. 1888–1894 елларда Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсендә укый. Төрек, гарәп, фарсы телләрен, ислам фәлсәфәсен, дин белемен, аннары рус телен өйрәнә. Күпмедер вакыт Бакчасарай шәһәренең «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә укып кайта, анда И.Гаспринский белән таныша.

1896–1901 елларда Казандагы Укытучылар мәктәбендә белем ала. Үзе укыган рус романнары тәэсирендә «Мәгыйшәт» исемле роман яза, ул 1898 елда басылып та чыга.

Садри Максуди француз телен өйрәнә һәм Париж шәһәрендәге Сорбонна университетының хокук факультетын тәмамлый (1902–1906).

1906 елда ул ватанына кайта һәм Россиянең сәяси тормышында актив катнаша башлый. «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясе лидерларының берсе була. 1907–1912 елларда II һәм III чакырылыш Россия Дәүләт Думасы депутаты итеп сайлана, татар һәм мөселман халыкларының хокукларын яклап чыгышлар ясый. 1908 елда Берлинда Парламентара берлек конференциясендә катнаша, 1909 елда Дәүләт Думасы делегациясе составында аларны Англия короле Эдуард VII һәм премьер-министр лорд Асквит кабул итә.

С.Максуди 1913–1917 елларда Казан мәхкәмә палатасында эшли. 1917 елда Бөтенроссия мөселманнарының Казанда узган II корылтаенда ул Милли-мәдәни мохтарият рәисе итеп сайлана. 1918 елда мохтарият таратылганнан соң, ул гаиләсе белән мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр була.

С.Максуди 1918–1924 елларда Финляндия, Германия һәм Франциядә яши, төрки халыклар тарихы буенча материаллар туплый. Сорбонна университеты профессоры һәм төрки халыклар тарихы кафедрасы мөдире булып эшли.

1925 елда Төркия Президенты Мостафа Кәмал Ататөрек чакыруы буенча гаиләсе белән Төркиягә күчеп килә. Төркиядә дә ул иҗтимагый-сәяси һәм гыйльми эшчәнлеген дәвам иттерә. Анкара, аннары Истанбул университетларында профессор вазифасын башкара, Төркия парламентына депутат булып сайлана, Ататөрекнең киңәшчесе була, төрек делегациясе составында бөтендөнья Милләтләр Лигасы конгрессларында катнаша, фән өлкәсендә төрки һәм Шәрыкъ халыкларының иҗтимагый хокукый тарихы, тел белеме, философия һәм социология буенча күпсанлы хезмәтләрен яза.

С.Максуди 1957 елның 20 февралендә Истанбул шәһәрендә вафат була.

Государственный и общественный деятель, один из лидеров татарского национального движения, правовед, ученый Садри Максуди (Садретдин Низамутдинович Максудов) родился 23 июля (по старому стилю) 1878 года в деревне Ташсу Казанского уезда Казанской губернии (ныне Высокогорский район Татарстана) в семье муллы.

Первоначальное образование получает у отца в сельском медресе. В 1888–1894 гг. учится в Казани в медресе «Касимия». Некоторое время учится и в Бахчисарае в медресе «Зынджирлы», там знакомится с И.Гаспринским.

В 1896–1901 гг. С.Максуди учится в Казанской учительской школе. Под впечатлением произведений русских писателей пишет роман «Мәгыйшәт» («Жизнь»). Этот роман был опубликован в Казани в 1898 году.

С.Максуди изучает французский язык и в 1902–1906 гг. учится на юридическом факультете Сорбоннского университета в Париже.

В 1906 году С.Максуди возвращается на родину и принимает активное участие в политической жизни России. Он являлся одним из лидеров партии «Иттифакъ әл-мөслимин» («Союз мусульман»). В 1907–1912 гг. избирается депутатом II и III Государственной Думы. На заседаниях Думы выступает с защитой прав татар и мусульманских народов. В 1908 году участвует в Берлинской конференции Межпарламентского союза, в 1909 году в составе делегации Государственной Думы был принят королем Англии Эдуардом VII и премьер-министром Асквитом.

В 1913–1917 гг. С.Максуди работает в Казанской судебной палате. В 1917 году на II Всероссийском мусульманском съезде, проведенном в Казани, избирается председателем Национально-культурного мухтариата. В 1918 году, когда мухтариат распускается, был вынужден эмигрировать с семьей.

В период с 1918 по 1924 гг. С.Максуди живет в Финляндии, Германии и Франции, собирает материалы по истории тюркских народов.

В 1925 году по приглашению Президента Турции Мустафы Кемаля Ататюрка с семьей переезжает в Турцию, где продолжает заниматься общественно-политической и научной деятельностью. Выполняет обязанности профессора в университетах Анкары и Стамбула, пишет многочисленные научные труды по истории тюркского права, языкознанию, философии и социологии. В годы правления Ататюрка С.Максуди избирается членом Национального Собрания, является советником Ататюрка, работает в Лиге Наций в составе турецкой делегации.

С.Максуди умер 20 февраля 1957 года в Стамбуле.

**Укырга тәкъдим итәбез:**
**Советуем прочитать:**

Максуди С. Миллият тойгысының социологик әсаслары /ТФА. Тарих ин-ты. – Казан, 1999. – 138 б.

Максуди С. Милләт вә миллият //Мирас. – 1995. – № 11-12. – Б. 150-151; 1996. – № 1-2. – Б. 207-211.

Максуди С. Мәгыйшәт: милли хикәя /[Р.Даутовның «Тарихыбыз офыгыннан исемнәр кайта...» дигән кереш сүзе б-н] // Казан утлары. – 1994. – № 7. – Б. 78-118.

Максуди С. Тюркская история и право. – Казань: Фэн, 2002. – 412 с.

Максуди С. Конституция культурно-национальной автономии татарского народа //Идель. – 1995. – № 5-6. – С. 54-61.

Исхаков С.М. Воззвание Садри Максуди к Парижской конференции: оригинал и переводы: [обращение датировано 10 января 1920 года] //TATARICA. – 2014. – № 1 (2). – С. 103-113.

Садри Максуди: тарих һәм хәзерге заман: Халыкара фәнни конф. материаллары. – Казан, 1999. – 256 б.

Садри Максуди (1878–1957): [мәкаләләр җыентыгы]. – Казан, 1996. – 160 б.

Гаффарова Ф.Ю. Садри Максуди (1906–1924 еллар). – Казан: Дас, 2001. – 262 б.

Гаффарова Ф.Ю. «Мин милләтемнең баласымын»; (олуг милләтпәрвәребез Садри Максудиның сәяси-иҗтимагый эшчәнлеге). – Казан: Иман, 1997. – 124 б.

Шәех Л. Садри Максуди //Кырык татар = Сорок татар = The Forty Tatars. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – Б. 196-202. – Татар, рус, ингл. телләрендә.

Айда Г. Садри Максудиның тормыш юлы //Мирас. – 1994. – № 4. – Б. 74-77.

Нуруллина Р. Максудилар нәселе кайдан килә? //Ватаным Татарстан. – 1994. – 23 дек.

Абдуллин Я. Садри Максуди – олугъ галим //Казан утлары. – 1996. – № 1. – Б. 141-149.

Таһиров И. Парижда укыган Садри //Йөртә безне язмышлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – Б. 147-157.

Гаффарова Ф.Ю. Садри Максудиның тормыш юлы //Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. – Казань: Мастер Лайн, 1999. – С. 291-302.

Айда А. Садри Максуди Арсал /[пер. с тур. В. Б. Феоновой; науч. ред., автор прим. и послесл. С.М.Исхакова]. – М., 1996. – 358 с.

Гайнанова М.Р. Мустафа Кемаль Ататюрк и Садри Максуди //Науч. Татарстан. – 2015. – № 1. – С. 36-41.

Багаутдинов Ф.Н., Гимадутдинов А.Н. Садри Максуди: юридическая деятельность //Науч. Татарстан. – 2009. – № 1. – С. 9-15.

Каримуллин А. Садри Максуди Арсал /[пер. с татар. Э.Нигматуллин] //Идель. – 1991. – № 10-11. – С. 88-95. – То же в парал. изд. на татар. яз.

Гаффарова Ф. Садри Максуди //Духовная культура и татарская интеллигенция: исторические портреты. – Казань: Магариф, 2000. – С. 147-154.

**9 сентябрь** **Лев Николаевич Толстой**
**9 сентября** **1828–1910**
**тууына 190 ел**
**190 лет со дня рождения**

Тормышлары Казан белән бәйләнешле атаклы рус әдипләренең берсе һәм безгә иң билгелесе, әлбәттә – Лев Толстой.

Лев Николаевич Толстой 1828 елның 9 сентябрендә Ясная Полянада туа. Әти-әниләре үлгәннән соң, 1841 елның көзендә яшь Толстойлар Казанга, туган апаларына күчеп киләләр.

Толстойларның Казанга килүе очраклы хәл генә булмый. Аларның нәселе күптән инде Казан белән якыннан бәйләнеш тоткан, кайберләре хәтта шунда яшәгәннәр дә. Толстой бабасының атасы Андрей Иванович Толстой, 1754–1759 елларда Казанда башта секунд-майор булып, аннары Свияжскида хәрби начальник булып хезмәт итә. Лев Николаевичның бабасы Илья Андреевич шулай ук яшьлек елларын Казанда үткәрә һәм 1815–1820 елларда хәтта Казанның губернаторы булып та тора. Ул Кизичье монастыре зиратына күмелгән. Язучының әтисе Николай Ильич та Казанга килеп, озак-озак торгалап китә. Николай Ильичның апасы Пелагея Ильинична исә Казан алпавыты В.И.Юшковка кияүгә чыга һәм бөтенләй Казан кешесенә әверелә. Пелагея Ильинична Юшкова бертуганының балаларын Ясная Полянадан Казанга алып килә. Леваның абыйларын (өчесен дә) Казан университетына, сеңлесен Затлы нәселдән булган кызлар институтына укырга урнаштыра, ә унөч яшьлек Леваны университетка хәзерләү өчен укытучы яллый.

Л.Н.Толстой 1844 елның 3 октябрендә Казан университеты философия факультетының көнчыгыш телләре бүлегенә беренче курска укырга алына. Югары катлауларның ваемсыз тормышы яшүсмер егетне үзенә тартып ала, күңел ачып йөреп ул укуларын калдыра, беренче семестр өчен имтиханнарын бирә ачмый, 1845 елның 13 сентябрендә ул юридик факультетка күчә. Бу вакытта Толстой күп укый, философия тарихы белән мавыга, үзе дә язарга тырыша. Ул шәхес буларак формалаша, үсә.

1847 елның 23 апрелендә Л.Н.Толстой Казаннан үзенә мирас булып калган Ясная Полянага кайтып китә.

Л.Н.Толстой Казанга берничә тапкыр килә. 1851 елның язында Кавказга барышлый ул абыйсы В.И.Юшковның авылында була, Родионов институты башлыгы Е.Д.Загоскинаның хәлләрен белә. 1862 һәм 1876 елларда Самара-Оренбур далаларына барганда да Казанда була.

Казанда Л.Н.Толстой яшәгән йортлар: өчәү башта ул Горталовлар йортында (Япеев урамы, 15 йорт) яши, аннары Киселевский йортына (хәзер Толстой урамы, 25) күчә, Казаннан китәр алдыннан бер елга якын Петонди йортында (Дзержинский урамы, 11) яши. Казанда язучы исемендәге сквер үзәгендә скульптор В.Б.Пинчук тарафыннан эшләнгән Л.Н.Толстой бюсты тора. Университетта укыганда Л.Н.Толстой «Черек күл» бакчасында да еш булган, ул да Толстой исеме белән бәйле урын булып тора. Бу турыда аның

Казанда алып бара башлаган һәм гомере буе алып барган көндәлекләрендәге язмалары күрсәтә.

Казан турындагы тәэсирләре, истәлекләре язучының хәтерендә нык сакланган һәм ул аларны үзенең иҗатында берничә мәртәбә кулланган. «Алпавыт иртәсе», «Балдан соң» хикәяләрендә, «Балачак», «Үсмерчак», «Егетчак» автобиографик трилогиясендә язучы гомеренең шушы чоры чагылдырылган.

2001 елның 27 сентябрендә Горталовларның элекке шәһәр утары булган урында Л.Толстойның музеен ачу турында карар кабул ителә. 2015 елның 29 августында, озакка сузылган реконструкциядән соң, ул Л.Н.Толстой исемендәге музей-укыту үзәге буларак ачыла.

Л.Н.Толстойның әсәрләре татар теленә дә тәрҗемә ителгән.

Л.Н.Толстой 1910 елның 20 ноябрендә вафат була.

Среди писателей, чьи славные имена связаны с Казанью, одно из первых мест принадлежит Льву Николаевичу Толстому.

Лев Николаевич Толстой родился 9 сентября 1828 года в Ясной Поляне.

После смерти родителей осенью 1841 года юные Толстые переезжают в Казань к своей тетке.

Семья Толстых имела давние связи с Казанью. Прадед Льва Николаевича – Андрей Иванович Толстой в 1754–1759 гг. служил здесь секунд-майором, а несколько позднее был воеводою в Свияжске. В городе прошла молодость деда – Ильи Андреевича, бывшего затем с 1815 по 1820 гг. казанским губернатором (похоронен на кладбище Кизического монастыря). Здесь в юности подолгу живет отец – Николай Ильич, а тетка Пелагея Ильинична, выйдя замуж за помещика В.И.Юшкова, навсегда поселяется в городе. Она и привозит в Казань осиротевших племянников. Льву Толстому было в то время 13 лет, для него были наняты учителя для подготовки в университет. В Казани проходят его юношеские годы.

3 октября 1844 года Лев Николаевич поступает студентом в Казанский университет на отделение восточных языков философского факультета. Братья его тоже учатся в университете, а сестра – в Институте благородных девиц. Но великосветская жизнь так захватывает юношу, что он пропускает занятия и не сдает экзамены за первый семестр. 13 сентября 1845 года он переходит на юридический факультет. В это время Толстой много читает, увлекается историей философии, пробует писать сам. Происходит его становление как личности.

23 апреля 1847 года Л.Толстой уезжает из Казани, получив в наследство Ясную Поляну.

Дома, где жил Л.Н.Толстой: почти два года его жизни проходят в доме Горталовых (ул. Япеева, 15), затем он переезжает в дом Киселевского (ныне ул. Толстого, 25), около года перед отъездом из Казани проживает в доме Петонди на бывшей Черноозерской улице (ул. Дзержинского, 11).

Л.Н.Толстой неоднократно посещает Казань. Проездом на Кавказ весной 1851 года он навещает дядю – В.И.Юшкова – в его деревне, начальницу Родионовского института Е.Д.Загоскину. В 1862 и 1876 гг., проездом в Самаро-Оренбургские степи, также посещает Казань.

Есть в городе памятник Л.Н.Толстому работы скульптора В.Б.Пинчука, который стоит в центре сквера, носящего имя писателя. Толстовским уголком является и сад «Черное озеро», где Толстой часто бывал в период учебы в университете. Об этом и свидетельствуют записи в его дневниках, которые он начинает писать в Казани и ведет всю жизнь. Казанские впечатления прочно сохранились в памяти писателя, он неоднократно использует их в своем творчестве. Этот период жизни находит отражение в рассказах «Утро помещика», «После бала», автобиографической трилогии «Детство», «Отрочество», «Юность».

27 сентября 2001 года на территории бывшей городской усадьбы Горталовых основан Музей Л.Н.Толстого. После многолетней реконструкции 29 августа 2015 года он открыт как Музейно-образовательный центр им. Л.Н.Толстого.

Произведения Л.Н.Толстого переведены на татарский язык.

Л.Н.Толстой умер 20 ноября 1910 года.

***Укырга тәкъдим итәбез;***
***Советуем прочитатъ:***

Толстой Л.Н. Анна Каренина: роман: 2 томда /[М.Максуд тәрҗ.]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960 –

Т. 1. – 1960. – 552 б.

Т, 2. – 1960. – 484 б.

Толстой Л.Н. Балачак: повесть /[кереш сүз язучы А.Поповкин; К.Миңлебаев тәрҗ.]. – Казан: Таткнигоиздат, 1955. – 147 б.

Толстой Л.Н. Балдан соң /[С.Әдһәмова тәрҗ.]. – Казан: Татгосиздат, 1953. – 18 б. – Биогр. белешмә: Б. 18.

Толстой Л.Н. Егетчак: повесть /[К.Миңлебаев тәрҗ.]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. – 180 б.

Толстой Л.Н. Казаклар: Кавказ повесте (1852–1862) /[К.Миңлебаев тәрҗ.]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 182 б.

Толстой Л.Н. Сугыш һәм тынычлык /[М.Максуд тәрҗ.]. – Казан: Таткнигоиздат, 1954–1957.

Т. 1. – 1954. – 420 б.

Т. 2. – 1955. – 438 б.

Т. 3. – 1957. – 466 б.

Т. 4. – 1957. – 396 б.

Толстой Л.Н. Үсмерчак: повесть /[К.Миңлебаев тәрҗ.]. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 100 б.

Толстой Л.Н. Хаҗи Морат: повесть /[Л.Гыйззәтуллина тәрҗ.]. – Казан: Мәгариф, 2000. – 208 б.

Толстой Л.Н. Яңадан туу: роман /[А.Шамов тәрж.]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 542 б.

Климентовский В. «Сәләтсез» студент //Казан утлары. – 1971. – № 5. – Б. 171-175.

Кашапова С. Толстойның Казан чоры хатирәләре //Мәдәни җомга. – 2017. – 6 окт. – Б. 8.

Сабиров Р. Лев Толстой һәм шәһәребез //Соц. Татарстан. –1989. – 1 окт.

Гайнуллин М. Дуслыкта – көч: публицистик мәкаләләр, әдәби очерклар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. – 247 б. – Толстой һәм татар әдәбияты. – Б. 74-83.

Кадыйров О. Тәрҗемәләр һәм цензура киртәләре //Казан утлары. – 1978. – № 9. – Б. 143-148.

Бушканец Е.Г. Юность Льва Толстого. Казанские годы. – Казань: Kazan-Казань, 2008. – 143 с.

Кадыров О.Х. Возвышение: Л.Н.Толстой в татарских переводах советской эпохи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2005. – 158 с.

Писарева С.В. Лев Толстой и Казань: по материалам выст.: буклет. – Казань: Рут, 20.., – 18 с.: ил.

Толстая А.Л. Отец. Жизнь Льва Толстого. – М.: Книга, 1989. – 503 с. – О казанском периоде жизни. – С. 33-43.

Климентовский В.А. Русские писатели в Татарии. – 3-е изд., доп. и перераб. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 176 с. – Л.Н.Толстой. – С. 80–98.

Коновалова С. Лев Толстой в Казани //Казанский альманах. – 2008. – № 1. – С. 83-94.

Коновалова С. «Я очень любил веселиться в казанском, тогда очень хорошем обществе…» //Татарстан. – 2012. – № 6. – С. 86-87.

Смирнова Н. Четыре Татьяны Льва Толстого //Республика Татарстан. – 2014. – 23 янв. – С. 16-17.

Смирнова Н. Казанская муза Льва Толстого //Казань. – 2013. – № 9. – С. 14-21.

Мамаева Т. Юшковы, родственники Толстого //Время и деньги. – 2008. – 24 июля.

Бушканец Л. Школа Толстого: о музейно-образовательном центре им. Л.Толстого в Казани //Казань. – 2015. – № 8. – С. 107-109.

**9 сентябрь** **Вера Минкина**
**9 сентября** **1918–2011**
**тууына 100 ел**
**100 лет со дня рождения**

Күренекле драма актрисасы Вера Егоровна Минкина 1918 елның 9 сентябрендә Казан губернасы Чистай өязенең Бахта авылында туа. Чистайда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Казанга килә, Татар сәнгать техникумының театр бүлегенә укырга керә. 1938 елда укуын тәмамлагач, аны Татар академия театрының колхоз театрына (соңрак Татарстан Республикасы күчмә театры, хәзер К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) эшкә билгелиләр. Ярты гасырдан артык, 1952 елдан 2004 елга кадәр актрисаның тормышы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры белән аерылгысыз бәйләнгән.

Актриса үзенең беренче ролен – театр филиалында М.Әблиев пьесасы буенча куелган «Шәмсекамәр» спектаклендә Разияны ышандырырлык һәм истә калырлык итеп башкара, зур осталык белән Ф.Хөснинең «Урманда»сында Галия, Р.Ишморатның «Гөлзадә» әсәрендә Гөлзадә), А.Н.Островскиийның «Соңарган мәхәббәт»ендә Людмила, М.Әмирнең «Тормыш җыры»нда Фатыйма, «Миңлекамал»ында Миңлекамал образларын иҗат итә.

Татар академия театры сәхнәсендә В.Минкинаның иҗат биографиясе яшүсмер егетләр рольләрен уйнаудан башлана; аның беренче роле – К.Тинчурин пьесасы буенча куелган «Зәңгәр шәл» спектаклендәге Малай образы. Т.Гыйззәтнең «Чаткылар» спектаклендә Гыйльмениса, Г.Камалның «Бәхетсез егет», «Банкрот» спектакльләрендә – Биби, Туганым, К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»рында Сәрвәр, Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр»ендә Екатерина һ.б. кебек характерлы рольләр башкарып, ул милли театр сәнгатенә зур өлеш кертә.

В.Минкина танылган татар сәхнәсе осталарының иң яхшы традицияләрен дәвам иттереп, үзенең актерлык сәләте белән милли театрыбыз тарихын баета. Искиткеч таланты, сәхнәдә хатын-кыз холкының бөтен нечкәлекләрен тоеп-аңлап уйнавы, кешелеклегә аңа онытылмаслык дистәләрчә образ тудыру мөмкинлеге бирә. Т.Миңнуллин әсәрләре буенча куелган спектакльләрдәге рольләр актрисаның иҗат биографиясендә аеруча әһәмиятле. «Әлдермештән Әлмәндәр»дә Хәмдебану, «Гөргери кияүләре»ндә Палый һ.б. шундыйлардан.

Вера Егоровна радио һәм телевидение тапшыруларында катнаша, кинофильмнарда төп рольләр башкара.

В.Е.Минкинага 1968 елда ТАССРның халык артисты, 1977 елда РСФСРның халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә.

В.Е.Минкина 2011 елның 20 сентябрендә вафат була.

Видная драматическая артистка Вера Егоровна Минкина родилась 9 сентября 1918 года в деревне Бахта Чистопольского уезда Казанской губернии. После окончания семи классов школы в Чистополе едет в Казань, поступает в театральное отделение Татарского техникума искусств. Закончив учебу в 1938 году, она была принята в колхозный филиал Татарского академического театра (позднее Татарский республиканский передвижной театр, ныне Татарский государственный театр драмы и комедии им. К.Тинчурина). Более полувека, с 1952 по 2004 год, жизнь актрисы была неразрывно связана с Татарским государственным академическим театром им. Г.Камала.

В филиале театра В.Минкина дебютировала в роли Разии в пьесе М.Аблеева «Шамсикамар». Создала такие образы, как Галия в спектакле «Урманда» («В лесу») Ф.Хусни, Гульзада (одноименная пьеса Р.Ишмурата), Людмила в «Соңарган мәхәббәт» («Поздняя любовь») А.Н.Островского, Фатыма, Минникамал в «Тормыш җыры» («Песня жизни») и «Минникамал» М.Амира.

Творческая биография В.Минкиной на сцене Татарского академического театра началась с исполнения ролей травести: один из первых образов – мальчик в спектакле «Зәңгәр шәл» («Голубая шаль») по пьесе К.Тинчурина (1956). Наиболее значительный вклад в национальное театральное искусство В.Минкина внесла исполнением характерных ролей, среди которых – Гильмениса в «Чаткылар» («Искры») Т.Гиззата, Биби, Туганым в «Бәхетсез егет» («Несчастный юноша») и «Банкрот» Г.Камала, Сарвар в «Сүнгән йолдызлар» («Угасшие звезды») К.Тинчурина, Екатерина в «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца») Ф.Бурнаша и др.

Продолжая лучшие традиции прославленных мастеров татарской сцены, своим актерским искусством В.Минкина обогащает историю национального театра. Самобытность дарования, тонкое понимание женской натуры, личные человеческие качества позволяют ей создать десятки ярких сценических образов. Особенно знаменательными в творческой биографии актрисы стали роли Хамдебану «Әлдермештән Әлмәндәр» («Старик из деревни Альдермеш»), Палый – в спектакле «Гөргери кияүләре» («Зятья Гэргэри») Т.Миннуллина. Вера Егоровна участвовала в радио- и телевизионных передачах, исполняла главные роли в кинофильмах.

В.Минкиной присвоены почетные звания: в 1968 году – народной артистки ТАССР и в 1977 году – народной артистки РСФСР.

В.Е.Минкина умерла 20 сентября 2011 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

Минкина В. Ак яулыгым кебек ак калдым: (гомер монологы) //Татарстан. – 1998. – № 10. – Б. 54-55.

Минкина В. «Халкым миңа – көч, сәхнә гомер бирде»: [әңгәмә /әңгәмәдәш Л.Хәбибуллина] //Шәһри Казан. – 2008. – 5 сент.

Минкина В. Вера апа рекорды: [әңгәмә /әңгәмәдәш Р.Муллаянова] //Ватаным Татарстан. – 2008. – 25 окт.

Гыймранова Д. Театрыбызның Акъәбисе //Мәдәни җомга. – 2008. – 5 сент. – Б. 11.

Әхмәтгалиева А. «Яратып туялмадым»: [тормыш һәм иҗат юлы турында] //Мәйдан. – 2008. – № 11. – Б. 128-137.

Әһлия Ф. Чулпан – таңның көзгесе //Идел. – 2003. – № 12. – Б. 64-73.

Гобәйдуллина-Камалетдинова Ә. Вера апаның яшь калу сере //Мәдәни җомга. – 2010. – 19 гыйнв. – Б. 17.

Әхмәтҗанов Г. Еллар аңа кагылмый да кебек... //Мәдәни җомга. – 2004. – 23 гыйнв. – Б. 12.

Мулланурова Р. Үзебезнең Вера апа! //Сөембикә. – 2004. – № 1. – Б. 14-15.

Хәбибуллина Л. «Миңа 100 яшькә хәтле яшәргә куштылар» //Шәһри Казан. – 2011. – 10 февр.

Минкина В. Гранд-Дама камаловской сцены – веселая старушка: /[беседа; записала А.Кадырова] //Веч. Казань. – 1997. – 15 апр.

Илялова И. Вера Минкина //Народные артисты. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – С. 99-102.

Илялова И. Я полюбила ваших старушек: открытое письмо В.Минкиной в связи с ее 80-летием //Респ. Татарстан. – 1998. – 25 сент.

**27 сентябрь** **Лотфулла Фәттахов**
**27 сентября** **Лотфулла Фаттахов**
**1918–1981**
**тууына 100 ел**
**100 лет со дня рождения**

Татар сынлы сәнгатен баетуга зур өлеш керткән рәссам Лотфулла Габделмән улы Фәттахов 1918 елның 27 сентябрендә Түбән Новгород губернасының Сергач өязе Анда авылында туа. Беренче рәсемнәре һәм хикәяләре «Пионер каләме» (1930 нчы еллар) исемле татарча балалар журналында басыла.

Л.Фәттахов 1931 елда Казанга килә. 1935–1939 елларда Казан сәнгать училищесында белем ала. 1939 елда Совет Армиясе сафларына алына, совет-фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша.

1946 елда Л.Фәттахов демобилизацияләнеп Казанга кайта. «Татхудожник»та (1953 елдан Татар сәнгать фонды), Татарстан китап нәшриятында һәм «Чаян» журналында эшли.

Рәссамның татар авылына, тарихи-революцион темаларга багышланган әсәрләре совет сәнгатенең классикасына әверелә: «Сабантуй» (1957), «Яңа буралар» (1959), «Революция комиссары Мулланур Вахитов» (1964), «9 май – Җиңү көне татар авылында» (1947), «Туган ил турында җыр» (1948), «Игеннәр өлгерде», «Рауза» (1952), «Авыл» (1960) һәм башка картиналарында авыл һәм аның кешеләренең милли романтик образын бик оста сурәтли. Рәссамның күп кенә картиналарында лирик тема киң урын ала: «Тынгысыз яшьлек», «Яз көне» (икесе дә 1958) һ.б.

Л.Фәттахов портрет жанрына мөрәҗәгать итеп, танылган шәхесләрнең – В.Ульянов, А.С.Пушкин, М.Горький, Г.Тукай, М.Җәлилнең, үзенең замандашларының, дусларының портретларын яза. Ул балалар юморы белән сугарылган картиналар сериясе иҗат итә: «Булыша, имеш» (1954), «Әни күрмәгәндә» (1956). Сатирик темаларга «Утырыш чире кагылганнар», «Гайбәтче» (икесе дә 1953) картиналарын атарга була.

Л.Фәттаховның зур график мирасын татар язучыларының әсәрләренә ясалган иллюстрацияләр тәшкил итә. Алар арасында К.Нәҗминең «Язгы җилләр» (1952), Г.Бәшировның «Намус» (1954), Г.Әпсәләмовның «Ак төннәр» (1965), Г.Ахуновның «Хәзинә» (1966) һ.б. бар. Шулай ук ул Ә.Нәваиның «Фәрхад һәм Ширин» поэмасы (1948), Л.Толстойның «Хаҗи Морат» (1953) һәм башка әдипләрнең китапларына иллюстрацияләр ясаган.

Л.Г.Фәттаховка 1957 елда ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, 1980 елда РСФСРның халык рәссамы дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул СССРның Дәүләт (1951) һәм Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт (1958) премияләре лауреаты.

Лотфулла Фәттахов күп күргәзмәләрдә катнаша. Аның картиналары республика күргәзмәләрендә, «Зур Идел» зона күргәзмәсендә, РСФСР һәм Бөтенсоюз рәссамнары әсәрләре күргәзмәләрендә куела. Эшләре ТР Дәүләт

сынлы сәнгать музеенда, Татарстан Республикасының Милли музеенда, Көнчыгыш халыкларының Дәүләт сәнгать музеенда (Мәскәү), Чувашстан Республикасы сәнгать галереясендә саклана.

Л.Фәттахов 1981 елның 17 июнендә вафат була.

Лотфулла Абдульменович Фаттахов, внесший большой вклад в татарское изобразительное искусство, родился 27 сентября 1918 года в деревне Анда Сергачского уезда Нижегородской губернии. Первые рисунки и рассказы публикует в татарском журнале «Пионер каляме» («Перо пионера», 1930-е гг.).

В 1931 году Л.Фаттахов приежает в Казань. В 1935–1939 гг. учится в Казанском художественном училище. С 1939 года – на службе в Советской Армии. Участник советско-финской и Великой Отечественной войн.

В 1946 году Л.Фаттахов возвращается в Казань. Работает в творческо-производственных мастерских «Татхудожник» (с 1953 – Татарский художественный фонд), сотрудничает с Татарским книжным издательством, журналом «Чаян».

Произведения Л.Фаттахова, посвященные татарской деревне, историко-революционной теме, становятся классикой советского искусства: «Сабантуй» (1957), «Свежие срубы» (1959), «Революционый комиссар Мулланур Вахитов» (1964). В картинах «Утро 9 мая – в татарской деревне» (1960) и др. Л.Фаттахов сумел создать национально-романтический образ деревни, её жителей. Во многих картинах художника отражена лирическая тема: «Юность беспокойная», «Весной» (обе – 1958) и др.

Л.Фаттахов обращается к жанру портрета, создает серию картин, герои которых – В.Ульянов, А.С.Пушкин, М.Горький, Г.Тукай, М.Джалиль, его современники и друзья. Он создает серию картин детского юмористического жанра («Помощничек», 1954, «Пока мама не видит», 1956), сатирической темы «Прозаседавшиеся», «Клеветник» (обе 1953).

Обширное графическое наследие Л.Фаттахова включает иллюстрации к произведениям татарских писателей: «Весенние ветры» К.Наджми (1952), «Честь» Г.Баширова (1954), «Белые ночи» А.Абсалямова (1965), «Клад» Г.Ахунова (1966) и др., а также к поэме А.Навои «Фархад и Ширин» (1948), к повести Л.Толстого «Хаджи Мурат» (1953).

Л.А.Фаттахову присвоены почетные звания: заслуженный деятель искусств ТАССР, РСФСР (1957), народный художник РСФСР (1980). Лауреат премии СССР (1951) и Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая (1958).

Л.Фаттахов – участник многочисленных выставок. Его произведения хранятся в Государственном музее изобразительных искусств РТ, Национальном музее РТ, Государственном музее искусства народов Востока (Москва), Чувашской художественной галерее идр.

Л.А.Фаттахов умер 17 июня 1981 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

Якупов Х. Дустыма мәрсия //Татарстан. – 1999. – № 1. – Б. 72-75.

Якупов Х. Дустым турында истәлек //Казан утлары. – 1988. – № 12. – Б. 164-128.

Галиуллина М. Сират кичкән талант //Мәдәни җомга. – 2015. – 8 май. – Б. 12-13.

Сафиуллин Ә. Исеме дә яши, иҗаты да //Ватаным Татарстан. – 2003. – 9 сент.

Кыямова М. Эскизларда калган гарасат //Шәһри Казан. – 2014. – 12 дек.

Әхмәт Р. Үскәч алма бер алмагачта, якыная ерак Сергачта! //Шәһри Казан. – 2003. – 14 нояб.

Елькович Л. Лотфулла Фаттахов. – М.: Сов. Художник, 1960. – 73 с.: ил.

Червонная С. Художники Советской Татарии: (мастера изобразительного искусства Союза художников ТАССР). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 464 с. – Фаттахов Лотфулла Абдульменович. – С. 345-350.

Рамазанова Ф. Тема сабантуя в творчестве Л.А.Фаттахова //Истоки и эволюция художественной культуры тюркских народов: сб. материалов конференции посвящ. Ш.Тагирову. – Казань, 2008. – С.179-181.

**28 сентябрь** **Әхмәтһади Максуди**
**28 сентября** **Ахметхади Максуди**
**1868–1941**
**тууына 150 ел**
**150 лет со дня рождения**

Педагог, тел галиме, нашир Әхмәтһади Низаметдин улы Максуди 1868 елның 28 сентябрендә Казан губернасы Казан өязе (хәзер Татарстанның Биектау районы) Ташсу авылында мулла гаиләсендә туган. Башлангыч белемне әтисеннән ала. 1881 елда Казанга килеп «Касыймия» мәдрәсәсенә укырга керә. 1890 елда мәдрәсәне тәмамлагач, шунда ук укытырга кала.

Ә.Максуди 1894 елда Төркиягә китә, анда яңа ысул мәктәпләрендә уку-укыту эшләре белән таныша, тәрбия, ислах юлларын өйрәнә, ә аннан кайтышлый Бакчасарай шәһәрендә кала, «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә укыта. Анда Исмәгыйль Гаспринский белән еш очраша.

1896 елда Ә.Максуди Казанга кайта, үзлегеннән укып имтихан тота һәм шул нигездә укытучылык эшен дәвам иттерә. 1903–1905 елларда Казан университетында ирекле тыңлаучы булып йөри.

Мөгаллимлек итүдән тыш, Ә.Максуди дәреслекләр төзү белән дә шөгыльләнә. Бу эшне ул ике юнәлештә алып бара. Тел турындагы хезмәтләре белән үзен педагог-лингвист итеп таныта. Ул «Төрки сарыфы» (1910), «Төрки нәхүе» (1910) исемле кулланмалар төзи. Аеруча шөһрәт казанган хезмәте – 1892 елда дөнья күргән «Мөгаллиме әүвәл» әлифбасы. Бу китап утыз мәртәбә басыла.

Ә.Максуди икенче төр дәреслекләрендә үзен дин белгече итеп тә таныта. Галимнең дини китаплары һәркемгә аңлаешлы, үз ана телебездә язылган.

Ә.Максудиның тагын бер зур хезмәте – ул унөч ел дәвамында (1906, 15 гыйнвар – 1918 ел, 20 июнь) «Йолдыз» газетасын чыгара.

Ә.Максуди Казанда беренче рәсми татар китапханәсе «Көтепханәи Исламия»не оештыра. Ул 1906 елның 2 гыйнварында ачыла, ә Ә.Максуди 1923 елга кадәр аның мөдире була.

